Шәһри КАЗАН

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 17 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 6 (5184)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КАРТАЯМЫНИ СОҢ ЙӨРӘК...

9 бит

4 бит

Балтачта сугымчы бригадалары барлыкка килгән

5 бит

Кызлар бабайларны кыйный

КӨН АВАЗЫ

Юк әйберне эзләп йөргәнче...

Яңа елдан, гадәттәгечә, яңа үзгәреш-тәртипләр керде. Аның берсе сыра белән бәйле. Гыйнвар башыннан сыра сатуның вакыты чикләнде. Шуның өстенә аны мәйданы 50 квадрат метрдан ким булган биналарда бөтенләй сатарга ярамый. Ел башының тагын бер яңалыгы – аракыга бәяләрнең берничә дистә процентка артуы. Болай булгач, безгә киләчәктә эчкечеләрнең кимүен көтәргә кала. Ә сез ничек уйлыйсыз, эчкечеләр кимерме икән?

Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА, шагыйрә:

– Безнең илдә мине бер нәрсә гаҗәпләндерә. Халыкка күптән мәгълүм булган нәрсәләр өстәгеләргә, нишләптер, бик озак барып җитә. Халык моның турында күптән чаң суга бит инде. Минем үземнең дә лифтларда, йорт чатларында сыра шешәләре тоткан кечкенә малайларны күреп сискәнеп киткәнем бар. Яңалыкларга, әлбәттә, сөенергә кирәк. Тик күңелемдә бер дә шатлык хисе юк. Халык начар гадәттән бик авыр арына шул. Шуңа балаларга кечкенәдән үк моны аңлата башларга кирәк.

Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН, «Шамил» мәчете имам хатибы:

– Эчкечелеккә каршы көрәшүдә бу кечкенә генә бер адым. Аңа карап кына эчкечеләр кимеми дип уйлаучылар бар. Мин андый фикердә түгел. Сыраны күңел өчен генә эчүчеләр бар. Андыйлар өчен бу, бәлки, сыра эчүне ташлауга бер сәбәп булыр. Юк икән, ул аны аптырап эзләп йөрмәс. Аракының зыяны, аның нәрсәгә алып баруы турында балалар бакчасыннан ук аңлата башларга кирәк. Һәм елына ике тапкыр гына түгел, һәрдаим сөйләргә тиешбез.

Рамилә ШАКИРОВА, газета укучы:

– Эчәргә уйлаган кеше барыбер җаен таба. Аракыга акчасы җитмәсә, йөз грамм салып бирә торган чәркәханәгә бара. Даруханәдән борычның спирттагы төнәтмәсен яки денатурат алып эчәчәк. Моның ише законнар белән генә эчүчелектән котылып булмый.

«ШК» газетасының 22 гыйнвар — сишәмбе санына алхәбәр

«Сөяк эзләгән маэмай шикелле, йөрибез урам буйлап. Тәрәзәсе калын боз белән капланган бер йортта бишле лампа яктылыгы шәйләнә. Беләбез, кызлар безне көтә. Әкрен генә тәрәзәгә чиртәбез. Эчтә ут сүнә».

Госман ГОМӘР. «Аулак өй»

«Айдар Хәлим – Татарстан Республикасының быелгы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә иң лаеклы иҗади, көрәшче шәхесебез! Аның иҗади хезмәттәшләреннән хөрмәт белән үтенеп сорар идем: «Айдар агадан соң гына», – дип, бердәм булып чыгарыгыз шундый карарыгызны».

Зиннур ЗАКИРОВ. «Айдар агадан соң гына»

Атнага 3 тапкыр чыга торган газетаның индексы – 54126.

ҺӘР ӨЙДӘ – КҮРӘЗӘЧЕ...

7 бит

Нурия ВӘЛИЕВА:

«ҮТКӘН ЮЛЫМ АВЫР БУЛСА ДА, САГЫНЫП ИСКӘ АЛАМ»

8 бит

«КЫЗЛАРЫҢ БОЗЫККА БАСКАН»

10 бит

«Шәһри Казан»да бергә кайныйк! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Сездән өйрәнергә була

КАЗАНГА ике көнлек эшлекле сәфәр белән өлкә губернаторы Сергей Боженов җитәкчелегендә Волгоград өлкәсе делегациясе килде.

Делегация вәкилләрен «Казан» халыкара аэропортында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов каршылады. Волгоград өлкәсе делегациясе ТР Премьер-министры Илдар Халиков белән бергә «Химград» технополисында булды. Кунаклар «Химград» эшчәнлеге, компаниянең технополис территориясендә урнашкан җитештерү урыннары, шул исәптән «Данафлекс-Нано» ЯАҖ продукциясе белән таныштылар. Шулай ук аларга Чистай урамындагы Су спорт төрләре сарае да күрсәтелде. Волгоград өлкәсе вәкилләре төзелеп килә торган 45 мең тамашачыны сыйдырырлык яңа футбол стадионы мәйданын карадылар. Волгоград өлкәсе губернаторы ТРда Агросәнәгать паркын булдыру тәҗрибәсе белән кызыксынды. Ул авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшмәкәрлек, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен матдитехник база белән тәэмин итү кебек юнәлешләрнең үсешен уңай бәяләде һәм бу мәсьәләдә Татарстан тәҗрибәсен өйрәнү мөмкинлеген карарга тәкъдим итте.

Аларга да ярдәм кирәк

ТАТАРСТАНДА Эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәге ачыла.

Татарстан Премьер-министры Илдар Халиков «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе турындагы» ТР Министрлар Кабинеты карарын имзалады, дип хәбәр итә Татарстан Икътисад һәм сәүдә министрлыгы матбугат хезмәте. Эшмәкәрлеккә ярдәм итү үзәге республика Икътисад һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү буенча төбәк һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру, шулай ук эшмәкәрлек субъектларының хокукларын һәм закон мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән хезмәтләр комплексын күрсәтү максатыннан ачылган.

Ташлама калырмы, юкмы?

ТАТАРСТАНДА студентлар өчен 2013 елда шәһәр яны поездларына ташламаларны саклау мәсьәләсе карала.

Күп еллардан бирле килә торган традиция буенча, мәктәп укучылары, башлангыч һөнәри, урта һөнәри белем бирү учреждениеләре һәм вузларның көндезге бүлекләрендә белем алучы студентлар шәһәр яны тимер юл транспортында 50 процентлы ташлама белән йөри. Ташламалы чор, кагыйдә буларак, 1 сентябрьдән 15 июньгә кадәр гамәлдә була. Ташламалы категорияне ташу нәтиҗәсендә, тимер юл транспорты предприятиеләренә алынмый калган керемнәрнең 95 проценты федераль бюджет хисабыннан, ә калган 5 проценты төбәк казналары хисабыннан кайтарыла иде. Тик быел тимер юл предприятиеләренә бу максатларга компенсация түләү өчен акчалар каралмаган. Кайбер төбәкләрдә ташламалар бөтенләй бетерелгән, кайберләрендә исә ташламаларны саклап калу мәсьәләсе әле һаман карала этабында. Татарстан да шул этапта. Компенсацияне каплау мәсьәләсе уңай хәл ителмәгәндә, 1 февральдән укучылар һәм студентларга поезд билетлары тулы бәясенә рәсмиләштерелә башларга мөмкин.

Ничек төшерсәң дә матур

КАЗАН турында уникаль фотосурәтләрдән торган фотоальбом дөнья күрде.

«Казань by Gelio» ул – Казанның 100дән артык төрле йөз-кыяфәт сурәтләре тупланган фотоальбом. Әлеге проект авторы – Интернеттан файдаланучыларның шактыена таныш фотограф-блогер Слава Степанов (Gelio). Ул Калининградтан алып Владивостокка кадәр – ил буйлап күренешләрне югарыдан һәм гадәти булмаган яктан ачудан тәм таба. Әлеге хезмәтнең дә үзенчәлеге – һәр фотосурәтнең гадәти булмаган ракурстан төшерелгән булуы.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлеге язучы-прозаик **Адлер Камил улы ТИМЕРГАЛИН**ның вафат булуын хәбәр итә һәм туганнарының, якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

ҖИР ҺӘМ КҮК

17-18 гыйнвар магнит кыры тотрыксыз булачак.
19-23 гыйнвар магнит кыры тыныч булачак.

Казан хәбәрләре

Социаль ипотека буенча быел 2016 фатир тапшырылачак

Башкалада узган ел күпфатирлы 89 яңа йорт сафка бастырылган иде.

ТӨЗЕЛЕШ

– Казан тарихында төүге мәртәбә елына, гомум исәптә, 1 миллион квадрат метрдан артык мәйданда торак файдалануга тапшырып, рекордлы күрсәткечкә ирешелде, – диде мэриядә узган киңәшмәдә шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Азат Нигъмәтҗанов.

795,8 мең квадрат метр торак мәйданын күпфатирлы 89 йорт тәшкил итә. Социаль ипотека алымында 29 йорт төзелде, шулардан 4189 фатир бирелде. Шәхси торак төзелешендә дә активлык күзәтелә. Узган ел тапшырылган 204,2 квадрат метр торак мәйданы – гражданнарның тырышлыгы нәтиҗәсе. Шәхси торак төзелешенә, дип алынган җир кишәрлегендә күпфатирлы йорт төзү рөхсәт ителми. Коммерция алымындагы торак төзелешендә катнашыр яки шәхси участоктагы күпкатлы йорттан фатир сатып алыр алдыннан шәһәр башкарма комитетының торак сәясәте идарәсеннән белешү мәслихәт.

Азат Нигъмәтҗанов әйткәнчә, Татарстан башкарма комитетында торак файдалануга тапшыру, 2005 ел белән чагыштырганда, 58 процентка арткан. Казан сафка бастырылган торак мәйданнары буенча, миллионлы шәһәрләр арасында, 3 ел рәттән беренче өчлеккә керә, ә Идел буе федераль округында – лаеклы әйдаман.

Казанда быел 720-770 мең квадрат метр мәйданда торак төзеп тапшыру ниятләнелә. Социаль ипотека алымында быелга расланылган планда башкалада 2016 фатир тапшыру каралган. Социаль ипотека йортлары Подаметьевская, Һади Такташ, Горсоветская урамнарында, Оренбург трактында һәм Юдино бистәсендә төзелә. Болардан тыш, коммерция алымында 614 мең квадрат метр торак төзеп файдалануга бирү максат итеп куелган.

УНИВЕРСИАДА сувенирларын халык белми

Казанда быелның июлендә узачак Студентларның халыкара Уенына биш айдан аз гына артык вакыт калды.

Автор фотосы

УНИВЕРСИАДА СУЛЫШЫ

Дамир БӘДРИЕВ

Уйлап карасаң, Универсиада сувенирлары белән шәһәрдәге бөтен сәүдә челтәре тулган булырга тиеш. Ләкин күп кеше әлеге сувенирларны тотып карау түгел, кайда сатылганын да белми. Бауман урамындагы сувенирлар кибетләрендә, урамнардагы һәм сәүдә нокталарындагы киоскларда Универсиада сувенирлары юк. «Аның өчен лицензия алырга кирәк бит», – дип аңлатты Бауман урамындагы сувенир кибете хезмәткәре. «Хорошев» сәүдә оешмасы үзенең Островский урамындагы һәм «XL» сәүдә үзәге янәшәсендәге кибет-киоскларында лицензия нигезендә Универсиада сувенирларын сату белән шөгыльләнә. Бу кибетчекләрнең дә әле яртысы мәйданын фейерверк продукциясе биләп тора. Универсиада сувенирларының төрләре аз, ә иң арзанлысы дигән әйбернең дә бәясе 150 сум. Шунлыктан, аларда сатып алучылар да сирәк кунак. Студентлар һәм укучылар дәррәү йөрсен өчен Универсиада символлы 30-50 сумлык продукция дә җитештереп сату оештырылсын иде.

2005 елда – Казанның меңьеллыгына чыгарылган сувенирлар Бауман урамындагы киоскларда һаман сатыла. Казанны яраткан кеше яки турист ул товарны әле сатып алырга мөмкин. Ә Универсиада сувенирлары спорт чарасы узганнан соң кемгә хаҗәт булыр икән?

ОЧТЫ-КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

— Чүп-чарга карап, халыкның яшәү дәрәҗәсе турында фикер йөртергә ярамый.

(«Эшлекле дүшәмбе»дә әйткән сүзләре)

СӘЛАМӘТЛЕК

Битлек алдыңмы әле?!

Грипп, ОРВИ халыкны тәмам борчуга салды. Бөтен кеше дару препаратлары җыя, авырудан сакланыр өчен битлек ала.

Казан даруханәләрендә дә соңгы көннәрдә битлек сатып алучылар бермә-бер күбәйгән. Әйтик, кайберләрендә сату 1,5 тапкырга кадәр арткан. Әмма даруханә хезмәткәрләре әйтүенчә, борчылырга кирәкми: битлекләр бөтен кешегә дә җитәрлек, аның запаслары гел тулыланып тора. Битлек кию вирустан саклануның бер чарасы. Моннан тыш, кул һәм борыннарны даими рәвештә юып тору, кеше күп җыела торган урыннарда йөрмәү дә авыру эләктерү ихтималын киметә.

Республикабыз районнарында да авыручылар байтак. Ә менә Түбән Камада авыручылар, үткән ел белән чагыштырганда, 2 тапкырга кимрәк, дип хәбәр итә «Татар-информ». Бер атна эчендә биредә 8 кеше грипп йөктырган. 500гә якын кешедә ОРЗ. Дуңгыз гриппы белән авыручылар биредә әлегә күзәтелми.

Соң түгелдер әле, соң түгелдер...

АБУНӘ-2013

Кышкы сукмак, кубәләктәй карлар оча, суык бабай килеп битнең очын үбеп китә, ә син, аяк астындагы карның җырын тыңлый-тыңлый, өйгә кайтып киләсең. Менә кайтырсың да, кайнар чәеңне эчеп, бер кат эшләреңне тәмамлагач, йомшак кәнәфиеңә кереп чумарсың һәм кулыңа китап, газета алырсың. Күңелгә шулай рәхәт, тыныч. Сүзләрем уйдырма түгел, редакциябезгә күпсанлы укучыларыбыз шалтырата, Яңа ел мәшәкатьләре белән газетабызга язылмый калганнар һәм инде безне юксынырга да өлгергәннәр. Кадерле укучыларыбыз, дусларыбызга, якыннарыбызга хәбәр итә аласыз, «Шәһри Казан» газетасын февраль аеннан башлап та алдырырга мөмкин. Ә инде кемнәрдер берничә ай өчен танышу ниятеннән генә газетабызга язылган икән, алар да почта бүлекчәләренә барып, алдагы айлар өчен дә акча түләп куюны кайгыртса иде.

«Шәһри Казан» газетасының биш айга язылу бәясе (февраль-июнь)

54126 индексы (атнага өч тапкыр чыга) белән — **327 сум 75 тиен**,

16076 индексы (пәнҗешәмбе саны) белән **174 сум 35 тиен** тора.

Кабат суыта

Хач ману бәйрәменә, гадәттәгечә, көннәр суытачак. Синоптиклар хәбәр иткәнчә, ял көннәрендә һава температурасы 20 градуска кадәр төшә.

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

ҺАВА ТОРЫШЫ

Татарстан синоптиклары фаразлавынча, республикага салкын һава торышы килә. Алдагы көннәрдә суыта барып, 19 гыйнварда – православие вәкилләренең изгеләштерелгән бәкегә чуму традициясе башкарыла торган Хач ману бәйрәмендә исә көндез – 15-20, төнлә 20-25 градуска кадәр салкын була, дип хәбәр итә ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе.

Димәк, урамга чыкканда җылы итеп киенергә онытмагыз. Әшеп, суык тидермәс өчен, анда озак йөрмәгез. Сәламәтлек турында сүз чыккач, шуны да әйтергә кирәк, бу көннәрдә Җирнең магнит кыры аеруча тынычсызланачак, дип кисәтә мәгълүмат чаралары. Астрофизиклар әйтүенчә, Кояшта Җир шарыннан да зуррак булган тап барлыкка килгән. Магнит кырының көчле энергиясенә ия булган тап Кояш дискы буйлап хәрәкәт итә икән. Тиздән, имештер, таптан протуберанцлар «ычкынып» чыгачак, аннан Кояш дәрләп китеп, ул Җирнең магнит кырын бик каты тынычсызландырачак.

Хач ману көне уңаеннан халык арасында «Хач ману салкыннары Раштуаныкыннан да уздырып китсә, иген уңачак» дигән сынамыш яшәп килә. Раштуада көннәр җылы булуын һәм синоптикларның фаразын истә тотканда, сынамыш буенча, быел, Алла теләсә, иген уңышы сөендерерлек булырга охшаган.

Салкын дигәннән, көннәр суык торганда без кешеләр генә түгел, кошларга да кыен. Гадәттә, нәкъ менә шул коры салкында ризык таба алмаган песнәк, сары һәм купшы чыпчыклар һәм башка вак кошлар үлә дә икән. Шуңа да хайваннар дөньясын саклау идарәсе халыкның канатлы дусларыбыз турында да онытмауларын сорый. Алар көнбагыш, җир чикләвеген (арахис) яратып ашый, оялары куелган киптерелгән җиләк-җимеш тә игътибарсыз калмас.

«Кош хокукы» өчен түләтәчәкләр

Узган атнада Владимир Путин Дәүләт Думасына яшәү урыны һәм вакытлыча яшәү урынын теркәү тәртипләрен бозган очракта җинаять эше һәм административ санкцияләр каралачагы турындагы яңа канун проектын кертте. Бу канунны чыгару нияте «резин йортлар» проблемасын, ягъни формаль мәсьәләләрне генә хәл итәр өчен пропискага керүчеләр һәм кертүчеләр белән көрәшүне максат итеп куя.

ВАЗГЫЯТЬ

Канун кабул ителә калса, теркәлү узмыйча яшәүче гражданнарны – 2-3 мең сум, ә торак хуҗаларын 2-5 мең сум штрафка тартачаклар. Эш урыныннан файдаланып, бер квадрат метрга бишәр йөз кешене теркәтүче түрәләргә исә штраф йөз меңнән биш йөз меңгә тикле үсәчәк. Шулай ук бу эш өчен өч елга иректән мәхрүм итү яки шул вакыт дәвамында мәҗбүри эшләтү дә каралырга мөмкин. Эш урыныңдагы кешеләрдән исә теркәлү тәртибен бозган өчен – 25-30, ә юридик затлардан 250-700 мең сум штраф түләтүләре ихтимал. Мәскәү белән Санкт-Петербургта монды тәртип бозулар өчен штрафларны тагын да арттыру тәкъдим ителә.

Россиянең Федераль миграция хезмәте башлыгы Константин Ромодановский сүзләре буенча «резин йортлар» турындагы яңа канун прописка буенча яшәмәүче, башка адрес буенча торучы йорт хуҗаларына кагылмаячак. «Бер адрес буенча фатиры булып, үзе бүтән адрес буенча яшәүчеләргә бу кагылмый... Без андыйлар артыннан куып йөрергә җыенмыйбыз, тынычлап яшәсеннәр. Әмма торак хуҗалары төрле алдашулар белән шөгыльләнмәсен өчен һәм ялган теркәлүгә каршы көрәшү ниятеннән, безгә нигез кирәк», – ди Ромодановский.

Шулай да хокук яклаучылар Президентның бу инициативасы белән килешми. Әлеге канун кешене конкрет яшәү урынына бәйләп куячак, аның хәрәкәт итү ирекен кысачак дип саныйлар.

Хәзерге канун буенча, гражданнар теркәлү урыны булмаган җирдә 90 көн дәвамында яши ала. Шул срок беткәнче теркәлү узарга кирәк. Яңа канун гамәлгә кертелә калса, канунсыз фатир арендалап торучыларга һәм арендага биреп торучыларга шактый кыенга туры килергә мөмкин. Кыскасы, хакимият кайда гына яшәсәң дә, гражданнарны күз уңыннан ычкындырмыйча яшәтергә җыена бугай.

«Аракы» дигән шайтан

Яңа елның беренче көненнән үк шешә белән дус кешеләрне борчуга салган, ә спиртлы эчемлекләр җитештерүчеләрне нык куандырган бер үзгәреш булды. Бу – аракы һәм башка исерткеч продукция бәяләренең берничә дистә процентка сикерүе. Хәзер кибеттә ярты литрлы кырык градуслы «аракы» дигән шайтанны 170 сумнан да арзангарак сатмыйлар.

Халкының сәламәтлеге бәрабәренә

Горбачевның «коры канун»ы гамәлдә булган аралыкта авызлыклап тотылган «яшел елан»ны 80 нче еллар ахырында тоткынлыктан азат итеп, аңа янә тулаем ирек бирелгән иде. Түрәләребез бу карарларын казнаның саегуына сылтады, янәсе, аракы – аны тулыландыруның төп чыганагы. Хөкүмәт ил бюджетына кагылышлы проблеманы үз халкының сәламәтлеге бәрабәренә чишүдән дә яхшырак нәрсә уйлап чыгара алмады. Нәтиҗәдә, «коры канун» кабул ителгәнче, ягъни 1985 елга кадәр илдә аракыга бәйле нинди хаос булган, 90 нчы елларда бу хәл яңадан әйләнеп кайтты.

70 нче еллар ахырында илдә «икмәк шәрабы»н «чөмерү» күләме рекордлы күрсәткечләргә җиткән булган. Россия Империясе заманында да, Сталин чорында да аракы кеше башына елына 5 литрдан да артык кулланылмаган, ә 1984 елда теркәлгән аракының күләме генә дә бер «борынга» 10,5 литрны тәшкил иткән, идән астында самогон кууны да исәпкә алганда, 14 литрдан да артып киткән. Кызганычка, ике ел гына хакимлек итәргә өлгергән «коры канун» илдә җинаятьчелек күләмен 70 процентка киметә, 10 процентка хезмәт җитештерүчәнлеген арттыра, аварияләр, һәлакәтләр, янгыннар кими, алкоголь белән агуланып үлү очраклары юк дәрәҗәсенә җитә, ирләрнең уртача гомер озынлыгы 62,4 яшьтән 65 яшькә кадәр озая, үлемнәр исәбе 20 процентка азая, туучылар саны инде 25 ел буе күрелмәгән дәрәҗәгә үсә.

«Коры канун» гамәлдән чыгуы белән, ике ел буе түзеп торган халык «баш төзәтергә» яңадан аракы кибетләренә йөгерә. Исерек баштан кылынган җинаятьләр, ирнең хатынына кул күтәрүләре, балаларын өйдән куып чыгарулары, шешәдәшенә пычак кадаулары, янгыннар, юл һәлакәтләре, сугышулар, талаулар, көчләүләр – болар барысы да янә иреккә чыгарыла. 90 нчы елларда Президент Ельцинның оператор тотып торган камера белән берәр чәркә чәкештереп, «якасы артына салып» куюларын телевизор аша күзәтү гадәти хәл булган. Ике ел буе аек тормышка «чыдау» нәтиҗәсе булгандырмы, 90 нчы еллар илдә төрле бандалар, группировкалар хакимлек итүе белән генә түгел, шул чорда, башка вакыт аралыклары белән чагыштырганда, алкоголизм чире чәчәк атуы белән дә мәгълүм.

2008 елга кадәр «чистай малаена» игътибар елдан-ел үсеп, соңгы елларда бераз кимүгә таба бара башлаган, дип исәпләп чыгарган белгечләр. 2008 елга чаклы бер кеше башына 15-16 литр (!) аракы туры килгән. Быелгы исәп-хисап мондыйрак: бер кешегә 12,5 литр аракы, 80 литр сыра, 9 литр шәраб һәм 1 литр коньяк.

Кайсы кадерлерәк — аракымы, акчамы?

Хөкүмәтнең аракыга каршы игълан ителгән көрәше ел саен «акбаш»ның бәясен арттырудан гыйбарәт. Моңа кадәр кулланылган көрәш чаралары: инандырырга тырышу, аек югга басарга өндәүләр, эштән куулар, исерек баштан кылынган җинаятьләр өчен җәзаларны кырысландыруларның файдасы ташка үлчим икәнен аңлагач, хөкүмәт халкы өчен кадерле булган икенче әйбер – кесә янчыкына бәрү ысулын уйлап чыгарды. Узган ел ярты литр аракының минималь бәясе 125 сумга, быел 170 сумга күтәрелде. Һәр яңа елның 1 гыйнварыннан бу бәя тагын да артып, 2020 елга 1000 сумга җитәр дип көтелә.

Исерек баштан соңгы вакытта гына кылынган очракларга тукталып китик. «Мәскәүдә руль артына салмыш килеш утырган ир машинасы белән автобус тукталышына килеп кереп, 3 кешене бәрдереп үтергән», «бергә утырып эчкәннән соң, шешәдәшләрнең берсе икенчесенең башын шешә белән сугып ярган», «Буада 31 яшьлек ир ялгызы гына яшәүче 73 яшьлек әбине көчләгән»... Россиядә ел саен кеше үтерүләрнең 65 проценты, сәламәтлеккә зыян китерүләрнең 71 проценты, хулиганлык гамәлләренең 90 проценты, юл һәлакәтләренең 45 проценты нәкъ тә исерек баштан кылына. Аракы 1000 сум тора башлагач, бу җинаятьләр санының бермә-бер кимиячәге көн кебек ачык.

НИХӘЛ, АВЫЛ?

Алексеевскида сөт кабул итү пункты ачылды

Республикабызның Алексеевск районы Зур Тигәнәле авылында яңа сөт кабул итү пункты ачылды. Биредә 8 районнан сөт китереләчәк, дип хәбәр итә Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, район чыганагына сылтама күрсәтеп. Эш процессы болай башкарыла: бирегә хуҗалыклардан һәм халыктан җыелган сөт китерелеп, аңа лабораториядә төрле яклап анализ ясала. Алга таба чистартылган һәм суытылган сөт йөк машиналарының махсус сыешлыкларына салына һәм шул машиналарда Уфа, Мәскәү һәм Түбән Новгородтагы сөт эшкәртү заводларына җибәрелә, анда әлеге сөттән йогыртлар, эремчек, сыр һәм башка сөт ризыклары әзерләнә. Сөтнең литрын 10 сумнан кабул итәләр, исәп-хисап көн саен ясала.

Машинаңны төзәттеңме әле?

Республикада авыл хуҗалыгы техникасын язгы чәчү эшләренә әзерләү бара. Республика хуҗалыклары 2013 елның мартына кадәр машиналарны төзекләндереп-әзерләп бетерергә тиеш. Тракторлар ремонтын исә 1 апрельгә кадәр тәмамлау зарур. Әлегә тракторларның әзерлеге 65 процентка тигез. Бүгенге көндә авыл хуҗалыгы машиналарын төзекләндерү буенча барлык районнарда да эш алып барыла. Азнакай, Апас, Актаныш, Алексеевск, Тукай районнарында темплар яхшы, диелә Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы сайтында.

«Яшел атна» башланды

Татарстанлылар Германияне яулый: алар биредә уза торган «Яшел атна-2013» Халыкара агросәнәгать күргәзмәсендә катнаша. Күргәзмә бүген ачылып, 27 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк. Россия павильонының ачылу тантанасы исә 18 гыйнварга билгеләнгән. Күргәзмәдә азык-төлек продукциясе белән беррәттән, орлыклар, авыл хуҗалыгы өчен җиһазлар, теплицалар һ.б. да тәкъдим ителә. Күргәзмә тәҗрибә аралашу һәм шул ук вакытта республикабызны чит илләрдә дә таныту чарасы булып тора.

Сәхифәне Чулпан НӘҖИПОВА әзерләде

Сугымчы эзләп аптырыйсы юк

Авылда мал чалу тиз генә башкарыла торган эш түгел. Хуҗа кеше иң элек барлык кирәкле коралларны – бавын, пычагын һ.б. хәстәрләп куйса, хуҗабикә исә үз чиратында ашау-эчү мәсьәләсен кайгырта. Мал чалган көн авылда бәйрәм санала, шуңа күрә табын да бәйрәмчә булырга тиеш. Шулай итеп, ярты эш инде эшләнгән дисәң дә була, тик хәзер сугымчыны гына табарга кирәк. Менә монысы бүгенге көндә авылда бер бәла...

ЯҢА ХЕЗМӘТ

Чулпан НӘҖИПОВА

Кая барыйм, кемне дәшим?..

Күп кенә җирдә авыл буйлап китсәң, мал чалырлык бер генә кешене дә таба алмассың. Кайсының аек көнен туры китереп булмый – андый кешенең үзе ни дә, эше ни. Ир-атларның күбесе бу эшкә алынырга курка да әле, күпләрнең исә җөлләп кулы күтәрелми. Мөгезле эре терлеккә түгел, кош-кортка кагылырга җөрьәт итмәүчеләре дә бар. Бөтен авылга бер мал чалучы булса, рәхмәт әйтәсең. Әмма бөтен кеше дә аңа баргач, чиратың килеп җиткәнне генә бик озак көтәргә туры килә. Бәлки, кайбер якларда малларны бетерүнең, азрак асрый башлауның да бер сәбәбе шулдыр? Авылларда мал чалу иң җаваплы һәм иң мөһим эшләрнең берсе булып тора. Кулы да тәмле булсын, чиста да эшләсен, шарты да туры килсен дисең бит әле...

Мал чалучылар хезмәте оеша башлаган

Соңгы вакытта исә авыл җирендә бу мәсьәлә дә хәл ителеп килә бугай. Җәйге чорда акчаңны түләсәң, бакчаң да сукалаган, печәнең дә чабылган һәм алып кайтылган кебек, сугым чорында да мал чалып кәсеп итүче төркемнәр оеша башлаган. Берничә кеше берләшә дә, төрле авылларга, хәтта районнарга да чыгып, мал чалу хезмәтен башкара. Балтачта да бар андый төркемнәр. Әле менә күптән түгел генә әлеге районда яшәүче Роза апалар да, үгезләрен суярга кирәк булгач, кеше эзләп мәшәкатьләнмәгәннәр, мал чалучыларга гына мөрәҗәгать иткәннәр. Аларның эшеннән бик канәгать калган алар. Мал чалыр өчен кирәк булган бөтен коралларны үзләре алып киләләр, бөтен эшне башкарып китәләр. Кыскасы, хуҗа кешегә бер мәшәкате дә калмый икән. Ике-өч сәгать вакыт эчендә иң зур эшләрнең берсе башкарыла да куя. Роза апаларга 3 кеше килгән. Егетләрнең бу кәсепкә керешүләренә инде бер генә ел түгел. Шуңа күрә заказлары да күп. Кыш айларында буш торган көннәре бөтенләй дә юк. Дөрес, сугымчыларның җәй көне дә эшләре җитәрлек анысы. Бер көнгә 4-5 хайванга кадәр чалырга туры килгәли икән. Халык алар белән 3-4 көн алдан ук килешеп-сөйләшеп куя. Мамадыш, Саба, Малмыж, хәтта Ульяновск якларыннан да, безгә килегез әле, дип шалтыратучылар бар, ди. Хезмәтләре дә әллә ни кыйммәт түгел: бер баш үгез чалган өчен 1000 сум акча сорыйлар. Ашау-эчүне хәстәрләүне дә таләп итмиләр. Хәер, озаклап утырырга вакытлары да юк инде, чөнки икенче бер гаилә дә түземсезлек белән аларны көтә.

Дөрес, мал чалучы төркемнәр арасында да төрлесе була: кемдер намус белән, барлык дин кануннары буенча эшли, ашыкмый-кабаланмый гына эшен чиста-пөхтә итеп тәмамлый. Икенчеләр исә акча эшләүне генә күздә тотып, ашык-пошык эшләп китү ягын кайгырта.

Мондый хезмәтнең таралу башлавы авыл халкы өчен бик файдалы. Бу кемгәдер хезмәт хакы булса, икенчеләрне зур мәшәкатьтән коткара бит әле.

Мал чалучыларга киңәшләр

– Хайванны чалырга бер көн кала ашатмаска кирәк. Су гына эчертегез. Нәтиҗәдә ашказаны һәм эчәкләр бушап калачак. Бу аның эчен алуны җиңеләйтәчәк, икенчедән, ит тә озаграк саклана.

– Чалыр алдыннан хайванны борчымагыз, кыйнарга һич кенә дә ярамый. Болар барысы да итнең сыйфатына тәэсир итә.

Сүз уңаеннан, бүгенге көндә республикада терлекчелек буенча күрсәткечләр тотрыклы. Ит җитештерү буенча 12 процентка арту күзәтелә, ә менә сөт җитештерү 1 процентка кимегән. Бу турыда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә җиткерде. Шулай ук ул республикага дуңгызларның Африка чумасы үтеп керү куркынычы булуын әйтте. Аның әйтүе буенча, Татарстанда рөхсәтсез, тиешле документларсыз һәм ярамаган урыннарда терлек продукциясен, бигрәк тә дуңгыз итен сату очраклары артып киткән, дип хәбәр итә «Татар-информ».

ИКМӘК КҮПМЕ ТОРА?

Узган елның төп үзенчәлекләреннән берсе – игенгә бәяләр арту булды. Нәтиҗәдә Россиядә икмәк-күмәч эшләнмәләренең бәяләре 5-10 процентка кадәр күтәрелде. Бәяләр артуның төп сәбәпләренең берсе исә күп кенә төбәкләрдә булган корылык. «Россельхозцентр»ның Татарстандагы бүлекчәсе ел ахырында беренче тапкыр Россия төбәкләрендә икмәк-күмәч эшләнмәләре бәясенә анализын үткәргән. Иң кыйммәт һәм иң очсыз икмәк кайсы төбәктә икән?

БУ – КЫЗЫК!

Ак ипи

Иң югары бәя Архангельск өлкәсендә (1 кг) – **66 сум**

Иң арзаны Удмуртия Республикасында (1 кг) – **32, 5 сум**

Кара ипи

Иң кыйммәте Вологодск өлкәсендә сатыла (1 кг) – **47 сум** (Дарницкий икмәге)

Иң түбән бәя Мордовия Республикасында (1 кг) – **21 сум** (Крестьянский икмәге)

Социаль ипи

Иң югары бәя Камчаткада (1 кг) – **32 сум**

Иң арзаны Калуга өлкәсендә (Крестьянский икмәге) (1 кг) – **16 сум**

PS. *Безнең кибетләрдә сатыла торган гадәти кара ипи – 650 гр, ак ипи – 550 гр.*

КАРА-КАРШЫ

Туйганчы сөтле чәй эчәр идем

Быел авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә, Россия хөкүмәте карары буенча, һәр литр сөткә киткән чыгымнарны каплар өчен, ярдәм буларак субсидияләр билгеләнәчәк. Чит илләрдә ул инде яңалык булмаса да, безнең илдә әлеге төрдәге ярдәм сөт җитештерү өлкәсендә беренче тапкыр оештырыла. Сез бүгенге көндә бездәге сөт бәяләреннән канәгатьме?

Равилә Юсупова, Балтач, Арбор:

– Ничек канәгать булыйк инде, әлбәттә, юк! Малларны асрар өчен сатып алынган азыклар белән чагыштырганда, сөт бәясе тиеннәр генә тора инде ул. Ә бит хәзер печәнен дә, ашлыгын да – барысын да сатып алабыз. Шулай да аз булса да алга китеш бар үзе. Сөтне берничә ел элек 4 сумнан да тапшырып йөрдек бит. Хәер, хәзерге 10-12 сумы да инде аның кибеттәге бәяләр белән чагыштырганда тиеннәр генә. Ут, газ бәяләрен даими рәвештә арттырып торалар бит, сөтне генә һаман бер бәядән җыялар.

Венера Сафина, Казан:

– Мин бөтенләй сөт алмыйм. Чәйне куертылган сөт белән генә эчәм, анысын да әле көнгә бер генә тапкыр. Ул күпкә очсызрак чыга: әйтик, бер айга 2 савыт куертылган сөт җитә, ә литрлы сөтне ким дигәндә айга 5-6 тапкыр алырга кирәк. Бүгенге көндә кибеттәге сөт бәяләре яныңа якын килә торган түгел – бигрәк кыйммәт. Хөкүмәт сөт җитештерүчеләргә булыша башласа, бәлки, сөт бәяләре бераз төшеп, аннары мин дә туйганчы сөтле чәй эчәр идем...

Шәһәргә көн саен яңа шәһәр хуҗалыгы техникасы кайта дип лаф оралар оруын, ул техниканың ни рәвешле эшләве генә караңгы. Мин, шәхсән, инде ничәнче ел рәттән кышын Ходай Тәгаләгә генә өмет итәм. Кар күпме ява – шуның кадәр кар өстеннән йөриячәкбез дә. Шәһәрнең үзәк урамнарында кырып-ялтыратып, реагент дигән нәрсәләрен мулдан сипсәләр дә, шәһәрдән чак кына читтә урнашкан урам-тыкрыкларга аларның тырнак очы да тими бугай. Мин әнә баланы алырга барган җирдән, өч полосасы булган урамда да батып калдым. Инде, Президент Рөстәм Миңнеханов әйтмешли, үземне «полуфабрикат» йөртүче дип тә атамас идем, йөртүче таныклыгы алганга да шактый...

Кайсыгыз МИНЕ этә?

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Кемнең кемдә эше бар

Менә шул – кырый полосадан барган җирдән машина шугалак өстендәге яңа туган бозау кебек бер урында тик биеп тора башламасынмы. Инде ир-егетләрнең бөтен киңәшен тыңлап, машинаны әле болай, әле тегеләй иткән булам. Көлгәнгә көлке инде – кем сиңа машина агымында туктап, ярдәмгә килсен. Арттан килүче ир-ат машина йөртүче дә «бии» башлагач кына миңа уңыш елмайды. Этеп-төртеп чыгарып җибәрделәр үземне. Абау, мәйтәм, авыл булып авылда мондый гыйбрәт күренешләр гайре табигый хәл бит инде – анда урамнарны туфрагы чыкканчы әйбәтләп кырып куялар. Ә без Казан уртасында ничарадан бичара булып гомер итәбез. Ул ишегаллары турында бөтенләй дәшмим дә инде. Кайсыгыз үзенең көрәлгән, ялт иткән, тоз яисә реагент сибелгән ишегалды белән мактана ала? Юк, ишегалды җыештыручылар эшенә тел-теш тидереп булмый. Алар тротуарларны кырып-себереп, ялтыратып куя. Анда аяк та таймый. Ә машина кәлиясеннән ишегалдыңа машинаңны кертеп кую тулы бер осталык таләп итә, каһәр! Аеруча алды гына тарткан машиналар өчен тулы бер цирк номеры – тездән кар боткасы астыннан ялтырап ятучы боз өстендә башка машиналарны «үпмичә» генә узып китеп кара син.

Кыш башыннан Казан урамнарыннан 167 мең тонна кар чыгарылган икән бездә. Шуның 40 меңнән артыгы гыйнвар аенда. Нинди генә яңа техникасы кайтып тормый бит әле аның! Бәйрәмнәрдә 591 техника туктаусыз кар чыгару белән мәшгуль булган әнә. Ике меңгә якын урамы булган Казан өчен бу ни дәрәҗәдә бүленә торгандыр, анысы билгесез. Әмма һаман шул үзәктә яшәүчеләргә көнләшеп үләрлек инде. Шәһәр читендә яшәсәң, Ходайдан гына сорыйсы кала. Яисә авылдагы кебек, көрәгең белән – «Алга!»

Үтми чана, үтми ат

Ә бала арбасы тарткан аналар, шактый түгәрәкләнгән көмәнле хатын-кызлар, өлкән яшьтәгеләр, авырулар ничек интегә? Нинди генә ораторлык сәнгате остасы, салпы ягыма салам кыстырып: «Бездә бар да яхшы, бездә бар да тәртип, кар чыгарылган», – дип сөйләсәләр дә, ышанасым юк. Күз буяу ич ул. Техника кайтты дип без сөйли торабыз, ник ялганлыйсыз, урамга чыгып карамыйсызмы әллә, дип укучыбыз шалтыратып әйтеп тора. Юк, ялганламыйбыз. Без дә сезнең кебек үк кар бетүен, тизрәк яз җитүен көтеп тилмерәбез. Кызым әнә тәртәгә тибә үк башлады: «Йә бу кар минем аякларыма комачауламый, йә мин бакчага бүтән бармыйм». Әллә мәйтәм миңа да эшкә барып кына тормыйсы шунда...

Булмый инде булмагач

Һәркемне алдап була, үзеңне генә алдый алмассың, дигән бер акыл иясе. Без дә хәзер шул үз-үзебезне алдау белән шөгыльләнәбез шикелле. Бар да яхшы диюдән аяк аслары гына чистармый да, атлап йөрүләре, машина йөртүләре генә ансатланмый. Ул ЖКХ тармагын күпме генә сүтеп җыймасыннар, ничек кенә реформалар үткәрмәсеннәр, әйләнә дә кайтып утыра бит анда шул бер үк кешеләр. Халык зарлана башласа, җитәкчеләрен алыштырган булалар, әмма һәр яңа скрипка шул бер үк көйне уйный.

Теш үтмәс, закон җитмәс бер орган бугай инде ул хәзер коммуналь хуҗалык. Югыйсә шәһәр урамнарында батып ятмас идек тә, ишегалларыбызда кар көртләре аркасында машинаны тротуар янына тери алмый интекмәс идек. Мин дә хәзер аңа якынлашканчы, янда кеше булу-булмавы турында хәсрәтләнә башлыйм. Кем әйтмешли, башта арттан этәреңне уйла, аннан машинаңны куярга маташ безнең Казанда...

Кызлар бабайларны кыйный

Бер көнне кадастрлар палатасына барырга туры килде. Фатир буенча вак-төяк документларны тәртипкә китерү тәки ел ахырына калды. Яңа елдан БТИ, кадастрлар палатасы башкарган эшләре өчен түләүне бермә-бер арттырып та алачагын белгәч, ничек тә барып чыктым мин анда. Минем кебекләр шактый җыелган, чират ишек төбеннән урамга ук чыккан иде.

Айсылу ИМАМИЕВА

Аякларның ут булып янганлыгы һәм ашыйсы килә башлауны исәпләмәгәндә сәгать ярымлап вакыт үткәнлеге сизелмәде дә. Әле тагын ярты сәгатьләп көтәсем барлыгын чамалап, уйлар дөньясына чумдым. Тик озак уйлана алмадым, җиргә кайтып кабинет ишеге төбендәге вакыйгаларны күзәтә башладым. Затлы хушбуй исе килгән елкылдап торган тун кигән бер кыз калын лупалы күзлекле җитмешне узган бер бабай белән сүз көрәштерә иде. «Сез башыгызны җүләргә салмагыз, электрон хезмәт күрсәтү дигән әйбер күптән бар, аны мин уйлап чыгармадым. Менә интернетка кердем дә кичке алтыга язылдым. Хәзер мине кабул итәчәкләр», – дип, кыз ишекнең тоткасына ук барып тотынды. Шунда теге бабай аңа каршы төште. «Минем интернетым юк, мин менә монда инде иртәнге сигездән бирле таякка таянып басып торам. Нәрсә генә дисәң дә, мин сине бусагадан да атлатмаячакмын», – диде. Шактый вакыт телләшкән кызның ярсуын бу минутларда берни белән дә сүрелдереп булмаячагы көн кебек ачык иде. Ул кабат-кабат үзенең интернет аша язылуын искәртә-искәртә тәмам туйды, күп уйлап тормады, бар көченә кизәнеп, мескен бабайның яңагына китереп сукты һәм: «Керт мине, хайван!» – дип кычкырды. Бабай аңа берни дип тә җавап бирмәде, әмма урыныннан да кузгалмады. Шунда теге кыз сакчыны чакырып бабайны куып чыгарырга куша башлады. Янәсе, ул оешманың кагыйдәләре белән санлашмый. Сакчы мин чиратта тәртип урнаштырырга тиеш түгел, үзегез хәл итегез, дип, кире борылып киткәч, бабайга икенче һөҗүм башланды. Сүз белән генә алдырып булмагач, кызның йодрыклары тагын төйнәлде һәм ул тагын да катырак иттереп теге бабайның башына, колакларына суга башлады. Монда инде халык кузгалды. Тавышгауга шул дәрәҗәгә җитте, мин кысылмыйм дип китеп барган сакчыга полиция чакыртырга туры килде. Бу турыда ишеткәч, барысы да тын булдылар, кыз бу хәлдән файдаланып, барыбер үзенекен итте: бабайдан алда кабинетка кереп китте. Күз төбе кызарган, колагы күпергән бабай авызын ачып карап калырга мәҗбүр булды. Теге кыз полиция килгәнче үк эшен бетереп чыгып тайды. Аны туктатырга җыенган сакчыга, өйдә кечкенә балам көтә, дип елап ишекне ачтырды.

Менә шулай кадастрлар палатасына барып кайттым. Дөньяда ниләр бар дисәң, хәзер кызлар бабайларны кыйный башлаган икән. Монда кемне гаепләргә дә белмәссең. Бәлки теге кызның нервлары какшагандыр, бәлки ул кешеләргә, аеруча олыларга хөрмәт булырга тиешлеген белми дә яшидер. Әллә үз дөреслеген исбатлап аның юлына каршы төшкән бабайдамы гаеп? Юк, һич юк. Бары тик электрон хезмәт күрсәтәбез дип халыкның башын бутыйсы калмагандыр. Интернет аркылы чиратка язылып була икән инде, андыйлар өчен аерым кабул итү бүлмәсен булдырсыннар йә аерым бер көннәрдә кабул итсеннәр. Сәгатьләр буе тере чиратта вакыт үткәреп арыганнарның башкаларны уздырасы килмәве– минемчә табигый күренеш.

Куркудан үләрсең...

Язгөлем МӨДӘРИСОВА

Ут бетсә, харап икән эшләр, җәмәгать! Әле ярый бу хәл 21 декабрьгә туры килмәде, дөнья бетә дигәннәре дөрес икән дип тәки куркуга бирелерсең.

Сәгать кичке сигезләр тирәсе. Матур гына телевизор карап утырганда, ут уйный башлады. Бер сүнә, бер кабына...Тыныч кына киноны карарга да ирек бирмәделәр, дип, зарланырга гына тотынган идем – шарт! Нидер булды. Нәкъ салют аттыргандагыча тавышлар чыкты, тәрәзәдән утлар чәчрәгәне күренде. Ни икән бу дип уйларга да өлгермәдем, бу шартлау тагын кабатлана башлады. Ут бөтенләй сүнде, фатирга әллә нинди сасы ис таралды, төтен керә башлады. Йөгереп урамга чыксам, янгын исе сулышны буа, безнең күпкатлы йортта яшәүчеләр барысы диярлек ишегалдында җыелышканнар. Кайсы чиләк белән кар, су тоткан, кайсы үзе белән документларын алып чыккан. Күршеләрнең кайберләре баткан корабльдән качкан тычканнар сыман йорттан ераккарак китә. Баксаң, безнең подвалда янгын чыккан икән. Кыска ялганыш нәтиҗәсендә ут чыбыклары яна. Моның яхшыга түгеллеген аңлап, тизрәк ике балам калган фатирга йөгердем. «Тизрәк киенегез, урамга чыгабыз», – дим. Ә өйдә дөм-караңгы. Балалар елаша. Кирәк чакта фонаре дә кабынмый бит аның. Киемнәре дә табылмый. Җитмәсә күңелгә шик өстәп шартлау да тынмый. Кыскасы, кулга нәрсә эләкте – шуны алып, ни табылды – шуны киеп ерак туганнарыбызга юл тоттык. Ничә ел күрешмәгән идек, сәбәп тә булды. Кич кунарга фатирга кайттык. Өйдә мунча диярсең – ис, подъездда – төтен. Ут юк. Әле ярый «дөнья бетүгә әзерләнеп» шәмнәр алып куйган идек, кирәкләре чыкты. Белгән догаларымны укып, йокларга яттык. Исле фатирда кечкенә сабыйлар белән йоклавы да куркыта бит әле.

Ут чыбыкларын алыштырганчы шактый вакыт узды әле. Телевизор юк, суыткычлар эри. Әбием элек керосин лампасы яктысында шәлләр бәйләдек дип сөйли иде, кая ул?! Шәм утында газета укыган арада да күзләрем авырта башлады. Җитмәсә кызым, телевизор кабыз, дип үтенә, ут юк дигәнне дә аңламый нарасый. «Миңа ут кирәкми, мультфильмны гына карыйсы килә», янәсе. Икенче көнне кичке тугызлар тирәсендә генә бирделәр утны.

Авыр икән утсыз, җәмәгать. Әле ярый су, җылылык бар. Барысы да бергә бетсә, Алла сакласын, кеше ачлыктан, суыктан түгел, куркудан үләр, валлаһи.



КАЕШ. Кирәкме, юкмы?

Берсендә кунакка баргач, танышымның биш яшьлек кызы минем аяк киеме эченә кәгазь тутырып куйган. Үзенчә шаяртмакчы булгандыр инде. Ләкин әнисе, моны белгәч, баласын нык ачуланды, тегесе нәрсәдер каршы әйттеме, ана кеше ярсып китеп кызына каеш белән сугарга ук тотынды, аннары бер кат майка кигән баласын салкын балконга озатты. Балкон тәрәзәсен шакый-шакый үрсәләнеп елаган бала хәзер дә күз алдымда.

Эльвира МОЗАФФАР

Баланы алып керергә теләгән идем дә, танышым: «Бала минеке, аны тәрбияләүдә кысылмагыз. Үзегезнекен тәрбияләгез әнә», – дип кенә җаваплады. Балаларга каеш кирәк аларга, алайса башка менеп утыралар, имеш. Уйланып калдым. Кайчакта кат-кат әйтеп тә тыңламаган баланы әллә чынлап та каеш белән куркытыргамы? Көчсез, кечкенә сабыйны кыйнап җиңү берни түгел анысы. Тик бу аны акылга утыртырмы? Икенче яктан, кыйнау – җинаять ләбаса. Статистика буенча, Россиядә соңгы елларда гына 4 мең әти-әни моның өчен җәзага тартылган. Үз туксаны туксан булып, гел каршы килеп торган «кирлемән»не нишләтергә соң? Җавап эзләп «Гаилә» гаиләне планлаштыру үзәгенең 2нче категорияле психологы **Лариса ФРОЛОВА**га мөрәҗәгать иттем.

«Балага һич кенә дә кул күтәрергә ярамый. Аны тыңларга гына түгел, ишетә белергә кирәк. Аның да олыларныкы шикелле үз проблемалары бар һәм аларга бала-чагалык, юк-бар дип кенә карарга ярамый. Сабый киреләнгән очракта аның күзләренә карарга, тагын да яхшырагы, кулыннан тотып үз бүлмәсенә кереп сөйләшергә, аның ни өчен борчылганын, нәрсә әйтергә теләгәнен аңларга тырышыйк. Әйтми икән – кыстамагыз, вакыты җиткәч, үзе ачылыр.

– Лариса, балачакта сабыйларны кыйнау нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин?

– Статистика буенча, кыйналып үскән балаларның 90 проценты үз гаиләсендә дә бу ысулны файдалана. Бала үз-үзенә бикләнә, агрессиягә бирелә. Сугу, кимсетү аның өчен гадәти нәрсәгә әйләнә. Әгәр үсмер баланы рәнҗетәләр икән, ул үз-үзенә кул салырга мөмкин. Бала үзеннән көчсезрәкләрне кыйнарга ярый дип уйлап, каты бәгырьле булып үсә, физик көч куллану проблеманы хәл итүнең бердәнбер ысулы дип аңына сеңдерә, баланың ата-анага хөрмәте кими.

– Әле ярый вакытында кыйнап акылга утыртканнар, тәртипле булып үстем, дип әйтүчеләр дә бар бит?

– Әйе, мондый кешеләргә ата-анасы, сиңа яхшы булсын өчен кыйнадым, дигәнне аңына сеңдергән. Тик тормыш иткәндә, бу барыбер калкып чыгачак. Балачактагы кыйнаулар эзсез узмый.

– Әйтик, бала урлый башлады ди, монда сукмый калу мөмкин түгелдер?

– Монысы инде икенче тема. Кызып китеп суккансың икән, баладан гафу сорарга кирәк. Ләкин мин шулай да аңлашу, сөйләшү яклы. Һәрвакытта да ата-ана бала өчен үрнәк булуын онытмасак иде. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, диләр бит. Олылар өйгә әйбер урлап кайта икән, баладан нәрсә көтәргә?

– Биш тапкыр әйтеп тә тыңлатып булмаган балага сукмас өчен ата-анага нишләргә?

– Эштән арып кайткан ата-анага киреләнгән баласына түзеп торуы чыннан да авыррак. Баланы утыртып исеме белән дәшеп, син, зинһар, утырып тор әле, мин бер генә сәгать ял итеп алыйм, бик арыдым, аннары сөйләшербез дисәң, яхшы. Аннары баланың кризис чорлары була, ул юктан көйсезләнә. Андый очракта игътибар бирмәскә кирәк. Дөрес, игътибар җитмәү дигән нәрсә дә бар. Монда сабый үзенә җәлеп итү өчен кычкыра, елый. Минем бер пациентым, әнисе аны күрсен өчен, суыткычтан күкәй алып вата иде. Тынычлану өчен махсус күнегүләр дә бар. Әйтик, саруың кайный, бала ачуны чыгара. Чыгырдан чыкмас өчен, 3 тирән сулыш алып стенага йә ишеккә, иң мөһиме каты җиргә терәлергә кирәк. Аннары сулышны чыгарып, «мин тыныч, сабыр» дип кабатларга. Яки душ керергә, һич югы кулны юарга була. Тискәре мәгълүматлар күбесенчә кулларда җыела. Гаиләдә бала белән мөнәсәбәтләрдә аңлашылмаучанлыклар килеп чыккан икән, кичекмәстән психологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бары белгечләр генә вакытында ярдәм итеп проблеманың нидә икәнен ачыклый ала. Ачуны басу, сулышны җайга салу, үзеңне кулда тотып калу ысулларына да психологлардан өйрәнергә була. Һәр гаиләнең үз традицияләре, уртак бәйрәмнәре булсын иде. Атнага бер генә тапкыр булса да бергә җыелып, көннең ничек узганын, кемне нәрсә кызыксындырганын, борчыганын уртага салып сөйләшсәң, һәркемгә рәхәтрәк, җиңелрәк булып китә.

Олылар кыйнаганда берни эшли алмаган кечкенә сабый, тукта әле, үсим генә, күрсәтәм мин сиңа, дигән уйны күңеленә сеңдереп калырга мөмкин. Вакыт үтү белән, әти-әнисенә үпкәсе сүрелсә дә, кемнәндер үч алу теләге барыбер яши. Юктан да кызып китә торган, усал, ачулы кешеләр азмыни әйләнә-тирәбездә?

Сүз уңаеннан: РФ Дәүләт Думасында «социаль патронат» кертү турындагы закон проекты каралган иде. Аның буенча опека органнары һәр гаиләдә балаларның үсү процессын тикшереп торачак. Яңа законның максаты – балаларны җәберләүгә юл куймау. Әгәр бала, әти-әни мине кимсетә, дип зарланса, гаиләне килеп тикшерәчәкләр. Баланың сүзләре расланса, гаиләдән баланы алырга да мөмкиннәр.

Замана башка да бит...

Гүзәл УРАЗОВА, Татарстанның атказанган артисты:

– Әле яңа гына Илдар белән балаларны каеш белән тәрбияләргәме, юкмы дип сөйләшеп утырдык. Безне бит кечкенә чакта каеш белән куркыталар иде. Үзебез балаларга кул күтәргән дә юк. Җәллибез, куркабыз. Күбрәк сөйләшеп аңлашырга тырышабыз. Психологларга барганыбыз юк. Илдар үзе психолог безнең. Гомумән, балаларыбыз тыныч, тыңлыйлар. Тик заманасы шундыймы, иркәрәк хәзер балалар. Шулчак менә каеш кирәк түгелме икән дип тә уйлап куябыз?!

Җырчы Илдар Хәкимов белән Гүзәл Уразова ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Олылары Эллари инде мәктәптә укый, аңа 8 яшь. Элларига исемне Гүзәл уйлап тапкан. «Татар исемнәре сүзлеге»ндә Иллария исеме бар. Ул шат күңелле дигәнне аңлата. «Кызыбызның исеме үзенчәлекле булган кебек, ул үзе дә үзенчәлекле булып чыкты. Сабыр, олыларча фикер йөртә, җырчы булырга хыяллана», – ди Гүзәл. Ә менә былтырның августында гына дөньяга аваз салган кечкенә кызга Камилә дип исем кушканнар. Илдарның да, Гүзәлнең дә карт әниләре Камилә исемле булган. Шуңа да бу исем бик якын Хәкимовлар гаиләсенә.

Алло, доктор!

Балалар бакчасында җил чәчәге белән авырыйлар. Безнең кызга да иярер дип көтәм. Шуңа да бу авыруга алдан әзерләнеп куясым килә. Ацикловер дигән мазь бетчәлләрне тизрәк бетерә дип ишеткән идем. Җил чәчәген ничек дәваларга?

Әдилә Гыйниятуллина, Казан

Сорауга 6нчы балалар сырхауханәсе врач-педиатры **Елена БОЙКОВА** җавап бирә:

Җил чәчәге – йогышлы авыру, ул һавада тарала һәм бик тиз йога. Гомумән алганда, бу әллә ни куркыныч авыру түгел. Авырганда баланың тәненә вак кызыл бетчәләр чыга, алар төрле урыннарда булырга мөмкин (чәч араларында, тамакта, җенес органнарында). Бер-өч көннән алар сулы бетчәләрне хәтерләтә һәм шартлый башлый, ахырдан кутырлый. Җил чәчәге вакытында тән температурасы 38-39 градуска кадәр күтәрелергә мөмкин. Авыру бер атнадан өч атнага кадәр дәвам итә. Гадәттә, җил чәчәге вакытында зеленка кулланабыз. Антигистамин препаратлар (аллергиягә каршы кулланыла торган супрастин, фенистил һ.б.) да азрак файда бирә. Кызганычка, бу авыруны дәвалауның бернинди ысулы да юк. Дөрес, хәзер бетчәләр нык кычкытканда, авыртканда баланың хәлен җиңеләйтә торган дарулар барлыкка килә башлады. Әмма алар бик кыйммәт – 800 сум тирәсе. Ә менә ацикловер алар рәтенә керми. Шуңа да мин бу мазьне кулланырга киңәш итмәс идем. Җил чәчәгенә каршы вакцина да салдырырга була. Түләүле хастаханәләрдә генә түгел, дәүләт сырхауханәләрендә дә бар алар. Дөрес, чикләнгән күләмдә бүлеп бирелә. Шуңа да без аны еш авырый торган балаларга салабыз. Җил чәчәге белән авырган бала үзенә гомерлек иммунитет ала.

Шәүкәт ГАЛИЕВ

Нәни кыз учына каз бәбкәсен кысып тоткан да әнисе янына килгән:

– Менә кыймылдамый хәзер! Мин аны би-ик яратам! Кысып-кысып кочакладым! – дип кулларын күкрәгенә кысып күрсәтә.

Инде берсен шулай «яратып» чирәмгә сузып салган икән.

* * *

– Каян алдың әти моның кадәр матур чыршыны?

– Танышлык белән, итәк астыннан...

Апаны чәнечмәдеме икән ылыслар?

* * *

Аяк атлаган саен кар шыгыр-шыгыр килә. Бала тыңлап бара.

– Итекләр кәбестә ашый! – ди.

Җидегән чишмәләрдә ничә йөзек?

Ринат НУРУЛЛИН

Җиде елга, җитәкләшеп,
Бер дәрья булып ага.
Үрелгән җиде инештән
Бер толымдай һәр елга.
Һәр инешкә җиде чишмә
Коя көмеш суларын.
Һәр чишмәгә йөзек
төшкән –
Санап бирче шуларны!

(Җиде елгага җидешәр инеш коя. Димәк, инешләр саны:7х7=49. Чишмәләр саны:49х7=343. 343 йөзек)

Сәхифәне Эльвира МОЗАФФАРОВА әзерләде

بسم الله الرحمن الرحيم

Иманлы СҮЗ

Күп белергә телибез дә инде... Кызыклы китап, гаҗит алып укырга яратмасак та, телевизордагы шоу-программаларның берсен дә калдырмыйбыз. Яңалык җыю белән бергә, башыбызга кирәкмәгән мәгълүмат та «ага». Бу «эштә» ярдәмне интернет-телевизор да мулдан күрсәтә бит. Үткән яңа ел каникулларын гына алыйк. ТНТ каналында күне буе барган «Битва экстрасенсов» тапшыруы бик күпләрне үзенә каратып утыртты.

Һәр өйдә — КҮРӘЗӘЧЕ...

БОРЧЫЛУ

Мәрьям АБДУЛЛИНА,
КФУ студенты

Динсез, имансыз халык шуны карап рәхәтләнде, күңеленә «ямь» тапты. Әти-әниләре янына сыенып, каникулдагы балалар да ышанып-бирелеп карады бу тапшыруны. Ел буе карап «туганнар»га әйләнгән багучыларыбыз, яңадән өебез түрендә утырган телевизор экраннарыннан үзләренең «тылсым»нарын күрсәтә бит! Экстрасенсларның да нинди бит әле, иң-иңнәре генә сайлап алынган: кайсы карга, кайсы кәҗә тәпие тотып килгән. «Ах» итеп карап утырасың инде. Ничек дөрес әйтәләр икән болар дип, баш артын кашып утыручылар рәхәтләнеп йөгерерләр иде янарына. Кайсыбызның гына үлгән әби-бабайларыбыз белән очрашып, теге дөнья хәлләре турында беләсе килми соң?! Әйе, «шәп» реклама бара бу каналдан.

Хәер, төрле ырымнарга, йолдызнамәләргә ышану, багучылык бүгенге көндә болай да модада. Үткәнне-киләчәкне әйтеп бирүчеләрнең бизнесы үскәннән-үсә бара. Шарлатаннарның кесәләре калыная барган саен, гөнаһ тавы ишәя генә. Чөнки Коръән-Кәрим сихер гыйлемен шайтан тәгълиматы, дип аңлата. Аллаһы Тәгалә «Бәкара» сүрәсендә: «...Ул сихерчеләрнең үзләрен сихергә сатулары – нинди ялган эш, әгәр шуны белсәләр», – дип әйтә.

Пәйгамбәребезнең хәдисендә дә: «Әгәр бер кеше йолдыз гыйлемен өйрәнсә, димәк, бу кеше сихердән бер өлеш алган булыр, әгәр күбрәк өйрәнсә, сихердән янә күбрәк өлеш алган булыр», – диелә.

Иманыбызның ныклыгы шуның кадәр генәдер инде. Без, үзебез дә сизмәстән, яңадан-яңа юк-бар ырымнар уйлап чыгара башладык. Беркөнне әни бик матур үрмә гөл алып кайтты. Күрше апа: «Ирләрне өйдән биздерә бу гөл», – дип чыгарып атарга җыенган икән аны. «Минем чыгып китәсе ирем юк», – дип, әни сөенә-сөенә өйдә «үрмәләтте» мескен гөлне. Эх, шундый гөлләрне чыгарып атып кына ирләр өйдә утырса, ишек өсләренә ат дагаларын беркетеп кенә бәхет ишелеп төшсә иде дә бит ул!

Үткәннәргә күз салсак, сихерчеләрне яндырганнар, хөкем иткәннәр. Ә безнең заманда бу шогыль һаман да колач җәя, чәчәк ата. Иң аянычы шул, моңа беркемнең дә исе китми: югарыдагылар да, матбугат та, дин кешеләре дә битарафлык күрсәтә. Дөрес, 80 нче еллар азагында телевидениегә үтеп кергән Кашпировский, Чумакларны тыйдылар тыюын. Тик чабылган билчән тармакланып чыккан кебек, аларга алмашка йөзләгән яңа маглар үсеп чыкты. Бернинди рухи азык бирмәгән мондый тапшырулар махсус эшләнә, халыкны адаштыра, Аллаһтан һаман саен ерагайта бара. Гөнаһ таратучы бу тапшыруларны карап вакытыбызны сарыф итеп утырганчы, әлеге вакытны һич югы берәр дини китапка багышласак, ике куяның койрыгын бергә тотар идек: дингә – вакыт, җанга – рухи азык.

> *Пәйгамбәребезнең хәдисендә дә: «Әгәр бер кеше йолдыз гыйлемен өйрәнсә, димәк, бу кеше сихердән бер өлеш алган булыр, әгәр күбрәк өйрәнсә, сихердән янә күбрәк өлеш алган булыр», — диелә.*

Өрәк

НӘСЫЙХӘТ

Бер сәүдәгәр өенә соң гына кайтып бара икән. Үз юлында ул койма буенда төн үткәрергә уйлаган кара тәнле картны күргән. Мескенне, балаларны куркытыр дип, берәү дә үз өенә кертми икән. Сәүдәгәр аны үз өенә чакырган, кайнар аш, чиста кием биргән, аерым бүлмәгә йокларга яткырган.

Төн уртасында, тәрәзә янында гына йоклап яткан карт, нииндидер шау-шудан уянып киткән. Ай яктысында ул тәрәзәдән керергә маташучы ике каракны күргән. Алар сәүдәгәрне үтереп, акчаларын урламакчылар икән.

Негр карты, кулларын күтәреп:

– Әй, нәрсә эшлисез анда? – дип кычкырып җибәргән. Караклар аннан куркып:

– Монда өрәк! – дип кычкырышып, тәрәзәдән сикереп төшкәннәр. Берсе аягын сындырган, икенчесе башын тишкән. Тавышка кешеләр килеп, каракларны тотканнар.

Пәйгамбәребез бик дөрес әйткән: «Кеше икенче берәүгә ярдәм итсә, Аллаһ аңа булыша».

(«Фатиха» татар-мөселман балалар календареннан алынды)

Динне бозык динчеләр боза

БЕЗНЕҢ ПОЧТА

Әлфия ФАЗЛЫЕВА

Кечкенә чагымда авылыбызның гыйбадәт кылу урыны булып саналган бер йорт тирәсенә тәравих намазын тыңларга йөргәнебез хәтердә. Бәйрәм көннәрендә авыл урамы тәмле ризык исләре белән тула, ә без, бала-чага, белгән догаларыбызны күңелебездән кабатлый-кабатлый, кесәдәге кул бармакларыбызны бөкләп, санап барабыз. Андый чаклар күңелгә, ничектер, серле дә, тылсымлы да тоела, хәтта нииндидер хисси югарылыкка күтәрелеп алган кебек буласың.

Намаз укырга җыелган картлар исә, әле авыл халкы бик авыр яшәгән ул чорда да, гаҗәеп пөхтәләр, сарык йонынан бәйләнгән оекбашларының чисталыгы аеруча күзгә ташланып тора иде. Ишегалдында картларның аяк киемнәре матур гына тезелешеп кала, ә үзләре шул ак оек-башлары белән йомшак кына басып, йортның түренә үтәләр. Дин кешеләре, дога кылучы картлар минем күңелемдә менә шундый матур, үрнәк алырлык чиста, пөхтә, тәртипле булып калганнар. Изге юлда йөрүче кеше шундый булырга тиеш тә инде, билгеле. Без татарларда дин тоту гадәттә менә шулай гаҗәеп матур төстә бара торган иде. Һәрхәлдә, пычрак урамнарда намаз уку, дога кылу очракларын безнең күргәнебез булмады. Мондый нәрсәләр белән мин Татар иҗтимагый үзәгендә берникадәр вакыт җаваплы сәркатип булып эшләгәндә беренче тапкыр очраштым. «Кинәт кенә дини булып киткән» кешеләр тизрәк үзләрен күрсәтеп калырга ашыктылар ул чакта. Моның өчен урам иң уңайлы урын иде, күрәсең... Хәзерге вакытта да теләсә кайда урынлы-урынсыз дога кылып, үзләрен изгеләргә тиңләп, тирә-юнендәгеләргә акыл сатып, урынсыз кисәтүләр ясап йөрүчеләрнең ниятләре чисталыгына карата ирексездән күңелдә шик туа. Вакытында тормышта үзләрен күрсәтеп калырга өлгермәгән, сәләте житенкерәмәгән килеш хакимлек, өстенлеккә омтылучылар, минемчә, бүгенге көндә үз урыннарын сәясәттә һәм дин өлкәсендә табарга тырышалар. Әле күптән түгел генә өстәл артында хәмер чөмереп утырганнар, инде сакал үстереп, ялук бөркәнеп, чын дини булып кыланалар.

Исебезгә төшерик әле, нинди акчаларга салынды соң хәзерге мәчетләр? Үзем белгән бер авылыбыз кешесен мисал итеп китерә алам. Советлар чорында кибет хуҗасы булып эшләп, алдап сатып, күп акчалар, зур байлык туплады ул. Белгәнебезчә, кирәк әйберләр «итәк астыннан» гына сатылган ул заманда, андый кешеләр алдында «тезләнүчеләр» бихисап күп иде бит. Көне-төне хәмер эчеп йөргән, авызыннан сүгенү сүзләре төшмәгән әлеге кеше, үзгәреш чорлары килгәч, дәрәҗәсен арттырырга тагын җай тапты. Олыгаеп беткәч, эчүдән туктамаса да, динле булып кыланды, мәчет төзергә акчалар биргән булып, исемен мәңгеләштерергә керешә. Менә шундый кешеләрнең акчаларына салынган мәчетләргә хуҗа булырга да шундый ук нәфесле кешеләр тартылдылар түгелме соң? Эшләп киткән мәчетләргә «яңа татарлар» сәдака ташыйлар, аларның сәдакалары да үзләре кебек «симез»ләр, «ялтырап» торалар! Дин юлына баскан, башкаларга үрнәк булырга тиешле кешеләр ул хәрам акчаларны бер дә чирканмыйча кабул итеп ала торалар, һәм алдакчы, бозык, угрыларны туры юлга күндерергә тиешле динчеләр үзләре үк шулар рәтенә баса баралар. Ә шул кәлләрне күреп торган мескен халык әле сәдакасын һаман бирер тора, боларның Ходай каршында кайчан да булса җавап тотачагына ышана. Тик, күпме генә керсә дә, мәчет байлыгы күренми... Югыйсә ул акчалар зиратларны төзекләндерергә, вафат булганнарны бушлай күмәргә, мескеннәргә булышырга, авыруларны дәваларга китәргә тиеш бит! Ирексездән юлдан язган күпме яшьләр тәрмәләрдә җәфа чигә, шуларга ярдәм итү нишләп мәчетләрдә гамәлгә кермәгән?

Әлеге сүзләрем белән һич кенә дә ихлас мөселманнарны үпкәләтәсем килми. Андыйлар динне лозунг урынына күтәреп йөрмиләр, үз күңелләренең чисталыгын саклап, гыйбадәтләрен тыйнак кына үтәп, үз фикерләрен башкаларга такмыйча, изгелек кылып яши бирәләр.

Редакциядән: Кызганыч, мондый фикерләрне җәмгыятьтә әле шактый ишетергә туры килә. Ә сез Әлфия ханымның фикерләре белән килешәсезме?

ИСЛАМ ЯҢАЛЫГЫ

Мәүлид бәйрәме җитә

28 гыйнварда Г.Камал исемендәге театрда пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәсәлләмнең туган көненә багышланган бәйрәм чарасы үткәрелә. Мәүлид бәйрәмендә вәгазьләр сөйләү, мөнәҗәтләр уку көтелә. Танылган дин әһелләре, җәмгать эшлеклеләре чыгыш ясаячак. Бәйрәм кичәсен Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте оештыра.

Интернетта мөселман радиосы эшли

Россия Мөфтиләр шурасы һәм Россиянең Европа өлеше Мөселманнары диния нәзарәте интернетта «Мирадио» проектын башлады. Хәзер http://miradio.ru/ сәхифәсенә кереп, мөселман радиосын тыңларга була. Хәзергә тапшырулар алты сәгатькә исәпләнгән, киләчәктә аны сигез, ә аннары унике сәгатькә кадәр арттыру күздә тотыла.

Радионың эшли башлавы һәм проектны тәкъдим итү турында рәсми рәвештә 27 гыйнварда Мәскәүдә Крокус Сити холлда Мәүлид бәйрәме уңаеннан узачак кичәдә игълан ителәчәк.

Гарәп теле дәресләре үткәрелә

Исхак хәзрәт исемендәге миллатара мәдәниагарту үзәге Казанның «Кабан арты» мәчетендә атнаның һәр сишәмбе көнендә кондезге сәгать уннан бергә кадәр өлкән яштәге хатын-кызлар өчен гарәп теле дәресләре уздыра. Шулай ук һәр пәнҗешәмбедә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен рус телендә «Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вәсәлләм хәдисләренә аңлатма бирү» дигән темага лекцияләр укыла.

Казандагы «Сөләйман» мәчетендә исә күзләре күрмәүче мөслимәләр өчен быелгы курслар башланды. «Ярдәм» милли ислам хәйрия фонды оештырган курсларга Россиянең төрле төбәкләреннән килгән сукырлар җыела. «Сөләйман» мәчете имам хатибы Илдар хәзрәт Баязитов хәбәр иткәнчә, хәзерге вакытта мәчеттә елына сигезләп курслар үткәрелә. Күзләре күрмәүче мөселманнар өчен быелгы ел үзенчәлекле булачак: җәйгә алар Казандагы Колахматов белән Серов урамнары кисешкән урында төзелүче махсус бинага күчәчәк. Хәзер бирелә эчке бизәкләү эшләре бара.

Мәдәни ГАВАМ

Актерны урамда туктатып, уйнаган образларын искә төшерәләр икән, аның өчен моннан да зур куаныч юктыр. Беркөнне Татарстанның атказанган артисты Нурия ВӘЛИЕВА артыннан: «Бу бит карчыклар ролендә оста итеп уйный торган артист», – дип калганнарын үземә дә ишетергә туры килде. Әйе, Нурия апаны тамашачы К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында башкарган «Гайфи бабай, өйлән давай!» спектаклендә – Абыстай, «Сүнгән йолдызлар»да – Фәрхи карчык, «Бәйрәм белән, кызлар»да – Әби һ.б. рольләре аша хәтерендә саклый.

«Үткән юлым авыр булса да, сагынып искә алам»

СӘХНӘ ЮЛЫ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Бәлки үзе дә балачактан ятим калып әбисе тәрбиясендә үскәнгә күрә, аның холык-фигыльләрен үзенә сеңдергәндер ул. Әй, ул бәхетсез балачак... Аны тыныч кына сөйли алмый Нурия апа. Репрессия еллары да аларның гаиләсен читләтеп үтми. Колхоз рәисе булып эшләгән бабасы, кешеләргә яхшылык эшлим дип, ашлык өләшә. Тик ул изгелеге үзенә начарлык булып кайта. Аны кулга алып, Суслонгерга озаталар. Тугыз баласы белән тол калган Заһидә кызы Гамиләне әтисенә азык-төлек тапшырырга дип шунда җибәрә. Тәвәккәл таш ярыр дигәндәй, кыз бернидән дә куркып тормый, Суслонгерга барып кайта. Гамилә оста куллы булуы белән дә тирә-юньдә дан тота. Яшьтән үк тегүен дә тегә, итеген дә баса. Тик гомеркәе генә бик кыска була. Иреннән аерылганнан соң, 34 яшендә, кызы Нурияне калдырып, мәңгелеккә китеп бара. «Әниең озакламый поезд белән кайта», – дигәч, кыз еллар буе аның кайтуын көтеп яши. Әбисенә биргән «Нигә башкаларның әниләре яшь, ә син карт соң?» дигән сораулары да җавапсыз кала аның. Туган ягы Кукмарага кайтып әнә шул поезд тавышларын ишеткән саен, артистның бүген дә үзәге өзгәләнә. Әбисен үз анасына санап йөргән кызга җиде яшендә генә бер сыйныфташы аның үз әнисе исән булмавын әйтеп сала. Шул чактагы үрсәләнүләре Нурия апаның һич исеннән чыкмый...

– Нурия апа, тормышның ачысын-төчесен татып үскән кызны сәхнә ничек сихерләде соң?

– Без мәктәптә укыганда, татар теле укытучылары сәнгатьле итеп укуга игътибар итәләр иде. Бүген дә шулай булуын телә идем мин. Үзем кечкенәдән үк поэмалар ятлый башладым. Аннары укытучылар белән бергә авылларда концертлар куеп йөрдек. Кичке мәктәптә укыган чакта, Саба районына конкурска баргач, анда жюрида утырган Г. Камал исемендәге театр артисты Бари Әшрәпов шигырь укыганымны күреп, мине чакырып китерде дә: «Сеңлем, синең тавышыңа театр өчен», – дип канатландырып җибәрде. Әнә шуннан соң артист булырга хыялланып яши башладым.

– Урау юллар аша булса да, хыялыгызга тормышка ашыргансыз...

– Мин башта тегү фабрикасында эшләдем. Артист булу минем өчен чынга ашмас хыял иде. Казанга театр училищесына дип килсәм, анда рус группасы гына туплыйлар икән. Шуннан соң Г.Камал исемендәге академия театрына кереп карарга булдым. Анда миңа Әлмәт театрына артистлар кирәклеген әйттеләр. Шунда китеп җиде ел эшләдем. Күренекле артист Дамирә Кузаева белән бер үк рольләрне уйнарга туры килде.

– Сәхнә корбаннар сорый, диләр. Сезнең иҗат юлында да андый мизгелләр булгандыр.

– Сәхнә корбаннар сорый, диләр. Сезнең иҗат юлында да андый мизгелләр булгандыр.

– Минем ирем булган кеше театрда эшләвемне яратмады. Әмма аңа карамадым, барыбер сәхнәне сайладым. Аннан соң безнең юллар аерылды.

– Казанга нинди җилләр ташлады үзегезне?

– Бервакыт Казанга гастрольләргә килгәч, режиссер Фәрит Хәбибуллин ул чактагы Күчмә театрга чакырып алды. 1979 елда гомерем әнә шул театр белән бәйләнде. Режиссерлар ни өчендер мине гел әбиләр ролендә күрде. Мин аларны үземнен әбием язмышын да күз алдында тотып уйнадым. Үткән юлым авыр булса да, мин аны сагынып искә алам.

– Театрда эшләгән елларыгызда кызыклы мизгелләр дә булгандыр. Аларын да күздән кичерегез әле.

– Бервакыт бер авылга килеп төштек тә фатирга урнаштык. Мин аулаграк урын эзләп абзар артына чыктым да исерек хатын ролен кабатлый башладым. Шунда мине үтеп баручы берничә хатын күргән булган. Төшке аш вакытында өйгә керсәм, кәнсәләргә чакырырга килеп җиттеләр. Тегеләр хатыннар мине, исерек дип, барып әйткәннәр икән. Шуннан соң колхоз рәисенә роль кабатлавымны аңлатырга туры килде. Аннары үземнән гафу үтенде.

Икенче бер авылда «Хыянәтче» дигән спектакль уйныйбыз. Мин сәхнәдә: «Совет властена каршы баш күтәрәсеңме?» – дип, Нуретдин Нәҗмиевкә табагач күтәрүем булды, яныбызга бер ир йөгереп менеп, аңа сугып та җибәрде. Шуннан соң пәрдәне яптылар. Элек халык спектакльне чынлап кабул итә иде бит. Әнә шул чактагы рольләрем төшләргә кереп йөдәтә. Аннары төрле артистларга пародияләр ясарга ярата идем мин. Заманында Рабит Батулла: «Сиңа эстрадага юмор буенча да китәргә була», – дигән иде.

– Сез моннан берничә ел элек театрдан да китеп бардыгыз. Рольсез дә утырмадыгыз югыйсә... Әбиләр ролендә гөрләтеп уйнар чагыгыз иде.

– Сәхнәне яратсам да, үз теләгем белән китәргә булдым. Тик әле һаман да сөйләгән монологларымны искә алам. Рольләремне ташламыйча саклыйм.

– Борчу-шатлыкларыгызны кем белән уртаклашасыз? Бүгенге көндә гаиләдә таянычыгыз кем?

– Кызым Айгөл тәрбиясендә яшим.Ул минем ышанычым да, терәгем дә.

НИ ХӘЛЕГЕЗ БАР?

Клара БУЛАТОВА, шагыйрә:

– Ирем белән бер көе генә яшәп ятабыз. Улыбыз авылда өй салып йөри. Март аенда Әлмәт Язучылар берлегенең 50 еллык юбилее булырга тиеш. Үзем анда ярты гасыр буе әгъза булып торам. Бүген дә шигырьләр язам.

Хәҗәр ШӘКУРОВА, Татарстанның халык артисты:

– Күптән түгел гәнә җиде ел тәрбияләп торган апамны соңгы юлга озаттым. Бу арада шифаханәгә барып ял итеп кайттым. Өебездән куначак өземли. Үзем дә дусларның хәлләрен белешергә йөрим. Театрда карыйсы премьералар да бар.

Нуриәхмәт САФИН, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты:

– Узган елдан бирле авырып торам әле. Мәскәүдә яшәүче кызыбыз Гөлнара кайтып китте. Сиргәрәк күрешкәнгә, оныгыбызны сагынып көтеп алабыз.

ШӘХЕСЛӘР ТОРМЫШЫННАН

Бер төчкерсәң бетә ул

Авылларда гастрольләрдә йөргәндә кайвакытларда артистлар клубта куныp калалар икән. Бервакыт артистлар иске мәчет сәхнәсенә тезелешеп яталар. Сәйдәшнең урыны кырда, тәрәзә янына туры килә. Зәмһәрир суык кыш була ул елны. Иртән артистлар торып мичкә яга башлый. Кайсыларыдыр җылыну өчен клуб эчендә йөгерергә тотына. Бары тик Сәйдәш кенә тормый ди.

– Салих, тор инде, нишләп ятасың? – диләр моңа.

– Әллә авырыйсыңмы? – дип янына килсәләр, Сәйдәш торырга тели, ләкин торалмый.

Сәйдәшнең чәче тәрәзә суына ябышып каткан икән: аның бозга каткан чәчен кубарып алу олы бер вакыйгага әверелә. Кемдер көлә, кемдер Сәйдәшне кызганып уфтана. Ир-егетләр пычак, балта белән боз чаба башлыйлар. Хатын-кызлар, кайчы тотып, Сәйдәшнең чәчен кыркырга тотыналар. Көчкә-иншалла Сәйдәшне бу тоткыннан коткаралар.

– И-и, салкын тияр инде! – дип борчылалар хатын-кызлар.

– Бер-ике төчкерсәң бетә ул! – ди Сәйдәш.

Сәхифәне Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде

ЯҢАЛЫКЛАР

Режиссерны искә алалар

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында режиссер булып эшләгән Кәшифә Тумашеваның тууына 110 ел тулды. Шул уңайдан театрда «Сакла, шартламасын» дигән спектакль күрсәтелде. Күргәзмә залында режиссерга багышланган истәлекләр дә куелды. К.Тумашеваның 28 гыйнварда аның туган ягы Балтач районы Нөнәгәр авылында да искә алачаклар. Әлеге чарада танылган артистлар Исламия Мәхмүтова, Наил Шәйхетдинов, Нуретдин Нәҗмиев, Әнәс Галиуллин, Зөфәр Харисов һ.б. катнаша.

Камаллыларны Мәскәүдә яраттылар

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы Мәскәүдәге гастрольләре уңаеннан, Татарстанның Россиядәге вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин белән очраштылар. Анда Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Наилә Гәрәева, Ринат Таҗетдинов, Ирек Баһманов һәм театр директоры Илфир Якупов катнашты. Алар Мәскәүгә гастрольләргә ел саен килү мөмкинлеген тудыру турында сөйләштеләр.

Камаллылар быел Оренбург, Самара, Пермь якларына гастрольләргә барырга җыена.

Драматург юбилеена бүләк

Узган елның октябрендә Түбән Кама Татар дәүләт драма театрына күренекле драматург Туфан Миңнуллин исеме бирелгән иде. Быел коллектив 12-14 февральдә драматургның туган ягы Кама Тамагы районында аның «Мәдинәм-гөлкәем» спектаклен тамашачы хозурына тәкъдим итәчәк. Аннары 15-17 февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында гастрольләре узачак. Алар Т. Миңнуллинның «Нәзер», А. Гыйләҗевнең «Яра», А. Ивановның «Гөнаһлы мәхәббәт» спектакльләрен уйнаячак.

Универсиада кунакларына гына таратыла

Татарстан композиторлары җырларыннан торган антология 23 гыйнварда Зур концерт залында тәкъдим ителәчәк. Аны Татарстан дәүләт симфоник оркестры җитәкчесе Александр Сладковский төзеде. Әлеге җыентык милли-мәдәни мирасны саклау өчен бик кирәк. Германиядә дөнья күргән әлеге антологияне тәкъдим итү өчен аның продюсеры да киләчәк. Дисклар сатуга чыгарылмый. Ул Универсиадага килүчеләргә бүләк итеп тапшырылачак.

«Җәйнең бер көнендә»

Камаллылар тарафыннан норвегия драматургы Йон Фоссе әсәре буенча «Җәйнең бер көнендә» дигән спектакль куелырга әзерләнә. Аны баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштерә. Әлеге әсәр Россиядә беренче мәртәбә куела. Башка спектакльләрдән аермалы буларак анда персонажлар исемсез. Тамашачы сәхнәдә Люция Хәмитова, Алсу Каюмова, Гөлчәчәк Гайфетдинова, Илнур Закиров һәм Алмаз Гәрәев кебек артистларны күрә алачак. Премьера 8-10 февральдә күрсәтелә.

КАРТАЯМЫНИ СОҢ ЙӨРӘК...

Әлфия АФЗАЛОВАга — 80 яшь

«Меңьяшәр кыз» мәгънәсенә ия Әлфия исеме юкка бирелмәгәндер аңа. Шулай булмаса, таң атты исә бер яңа исем, бер моңлы тавыш иясе барлыкка килеп торган Татарстан өчен дә һаман бердәнбер булып кала бирмәс иде ул. Шушы көннәрдә генә үзенең 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче Әлфия Афзалова өчен үткән еллар да, сүтелгән иҗат гомере дә үз эченә асыл мәгънәне сыйдыра алган шул.

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

1933 елның 15 гыйнварында Актанышта туган кызның язмышы үзе үк бәгырьгә сеңгән моң төшенчәсе белән бәйле. 5 яшендә әнисез, соңрак сугыш зәхмәтендә әтисез калган сабый ничек моң-сагышсыз булсын да, ничек хәсрәт ачысын татымый гына үссен соң? Үзәккә үткән ятимлек гомер буе аның янәшәсендә атлап бара дисәң дә, арттыру булмас. Шуңа үзе дә ятимнәргә, үксезләргә битараф түгел – кулдан килгәннең һәр барчасы Әлфия тарафыннан эшләнеп килә.

1952 елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә эшли башлаган Әлфия Афзалова репертуары халыкта С.Габәши, М.Мозаффаров, А.Ключарев, З.Хәбибуллин җырлары аша танылу ала. Урта Азия һәм Балтыйк буе республикалары, Мәскәү, Ленинград, Башкортстан, Татарстан буенча сузылган гастрольләр. Ике-өч айлык андый гастрольләр кысасында йөзәр концерт куеп кайта моң патшабикәсе. Ике-өч ай!.. Безнең бүген, аһ-вах килеп, гастрольләргә чыгып китәбез дип сөйләшкән җырчылары-быз белән чагыштырганда, кызык та булып китә. Иртә китеп, кич кайта торган гастрольләр заманында, китап укырга вакыт юк, матбугаттан бихәбәр, дип утыручылары да шактый бит әле аның... Әлфия апа исә әнә шул ике-өч айлык гастрольләре вакытында матбугатка язмаларын биреп барырга да вакыт тапкан әле!.. Барлыгы 14 телдә җыр башкара белүче татар кызы, милләт кызы өчен гаҗәп тә түгел кебек – әмма ул зур үрнәк, зур хөрмәткә лаек мисал.

Әлфия Афзалова белән моннан биш ел элек әңгәмә корганмын икән. Ул вакытта үзенең өендә кабул иткән якташым, гап-гади кеше, олы шәхестән аерыла алмый интеккәнем истә. Биографияле, тормышның ачысын-төчесен күргән, һәр нәрсәне бөртекләп булдырган, халык мәхәббәтенә таланты янына тырышлыгын куеп ирешкән орчык гәүдәле Әлфия апага кем генә сокланмый кала алсын ди! Күзләре ут янып тора, теленнән юмор коела, җаныннан моң ташыган моң патшабикәсе шул ул!

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Г.Тукай исемендәге премия лауреаты Әлфия апа Афзалова турында күпме язылса да, күпме сөйләнсә дә, туйдырмый кебек. Әллә таланты-моңы, әллә гадилеге-кешелекле булуы, әллә артистлыгы үз эшен эшли.

Мәңге яшә, Әлфия апа! 80 яшьлек юбилееңүңаеннан «Шәһри Казан» гына түгел, бөтен татар милләте сиңа шулай дип дәшә. Әле син бик кадерле, әле син бик кирәк! Халык биргән исемең – моң патшабикәсе булып, ирешкән уңышларыңның төмен, тамашачыңның яратуын тоеп әле яшәргә дә яшәргә язсын сиңа. Үзең әйтмешли, ут янып торган йөрәккә еллар санап интекмик:

Картаямыни соң йөрәк,
Маңгайлар сырланса да...

Фәридә ӘХМӘТШИНА,
Татарстанның атказанган артисты («Фәридә – Алсу» дуэты җырчысы):

– Әлфия апа кебек бик зур тәҗрибәле, шундый мәртәбәле иҗат юлы узган башка хатын-кыз җырчыларыбызны атау да кыен. Ул ничә яшьтә булуына карамастан, һаман да энергияле, көч-дәрманлы кеше, анда кояш үзе көлә. Бүгенге пассив, пессимист яшьләргә аннан күпме үрнәк аласы бар! Мин үзем аңа караган саен сокланып туймыйм. Үз әбием белән дә чагыштырып куям кайчак – алар чордашлар. Әлфия апа елларны да җиңә ала торган кеше. Нинди формада ул, ә нинди матурлыкка ия! Мине иң сөендергәне исә – аңа булган дәүләт игътибарыдыр. Бездә бит гадәттә кеше арабыздан китеп баргач кына аңа карата игътибар күзтелә. Әлфия апа, шөкер, андый игътибарны исән вакытында күрә – аның өчен мин җитәкчелеккә рәхмәтле. Исән булсын иде Әлфия апа, сызланмасын, күзләрендәге яшәү очкыны гел балкып торсын.

Артур ИСЛАМОВ,
М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры, Петербургның Мариинский театры солисты:

– Әлфия Афзалова – бөек җырчы, бөек шәхес. Тормыш авырлыклары күрсә дә, ул – үзенең көчле рухлы, ныклы кеше, искиткеч талантлы җырчы булуын раслый алган кеше. Минем өчен дә ул зур үрнәк. Без бер яктан – Актаныштан булу икеләтә куанычлы. Мин шундый якташым булу белән чиксез горурланам. Юбилее уңаеннан исә Әлфия апага үз җырын җырлап китәсем килә:

Картаямыни соң йөрәк,
Маңгайлар сырланса да...

Мәңге яшә, Әлфия апа!

Рәсим НИЗАМОВ,
Татарстанның атказанган артисты:

– Әлфия апа Әлфия апа инде ул. Аның турында ни әйтсәң дә, әйтеп бетереп булмыйдыр. Ул – бердәнбер. Әлфия апа дигәндә, минем күз алдыма Илһам абый килеп баса, Илһам абый дигәндә, Әлфия апабыз... Алар икесе – безнең сәнгатьнең бердәнберләре, йөзек кашлары. Алар безгә – җырчыларга, иҗатыбызның теләсә кайсы дәверендә зур үрнәк булып калырлык шәхесләр. Аның үткән юлы, иҗади батырлыклары, күңел халәте, репертуары татар милләтенең байлыгына әйләнгән. Мин Әлфия апаны ихластан юбилее белән котлыйм, озын гомер телим. Бертуктаусыз җырласын, димим, бу яшьтә ул җиңел хезмәт түгел, исән булуы белән сөендереп торсын.

Резеда ГАЛИМОВА,
Татарстанның халык артисты:

– Әлфия апа белән моннан берничә ел элек Ташкент якларында концерт биреп кайтканым булды. Мин анда данлыклы җырчыбызны кеше буларак ачтым. Аның кадәр гади, аралашучан, балкып торган кешене күргәнем дә булмагандыр әле. Кәефе һәрвакыт шәп, беркемгә күңелсезләнергә, боегырга ирек бирми ул. Тормышны ярата. Мин әлеге сәяхәттән энергия һәм рәхәтлек алып кайттым. Без сине бик яратабыз, Әлфия апа. Шәхес буларак та, зур хәзинәле иҗаты булган җырчыбыз буларак та син безгә бик кирәк. Шуңа да мин аңа сәламәтлек, Татарстанның һәм Россиянең бөтен тарафларыннан үз иҗаты белән сөендергән җырчы буларак, иҗат дәвамы, балалар игелеге телап калам!

МӘСКӘҮЛӘРДӘН СӘЛАМ

Константин Меладзега 8 ел төрмә яный

Ел ахырында данлыклы композитор һәм продюсер тормышында коточкыч вакыйга булган икән. Киев-Обухов трассасында Меладзе үзенең «Лексус» машинасында хатын-кызны бәрдереп үтергән. Җәяүлеләр өчен юл кичүе – зебрадан чыгып баручы Анна исемле хатын-кызга нибары 30 яшь булган. Әчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте җиткерүе буенча, **Константин Меладзе** аек булган, документлары да тәртиптә икән. Хәзер эш хокук яклау органнарында, унлап экспертиза уздырылырга тиеш. Эшне караучы тикшерү маддәсе буенча, Меладзе 8 елга ирегеннән мәхрүм ителергә мөмкин.

Водонаева аерылышмый

Соңгы арада Алена Водонаеваның шәхси тормышы тирәсендә шау-шуның тынып торганы юк. Аларның иң актуале – телевидение алып баручысының аерылышуы турындагысыдыр. Күптән түгел генә Аленаның тәнһәрен йоклый алмый интегүе турында белсәк, кичәле-бүгенле исә шатлыклы хәбәр йөри. Алена ире бизнесмен Алексей Малакаев белән аерылышмый икән. Бүген очрашуларына 6 ел тулган пар гаилә булып озак яшәми яшәвен. Алар 2009 елда гына өйләнешкәннәр иде, уллары Богдан үсеп килә. Әмма чыш-пышның тынып торганы юк. Моңа Алексейның эше җирлек тудырамы, Аленаның реалити-шоуларда югалып торуымы – белмәссең...

«ВИА Гра» төркеменә кем бара?

Меладзеның шундый күңелсез тарихка эләгүе генә «Хочу в ВИА Гру» реалити-шоуына зыян салмаячак икән. Әлегә аның белән режиссер һәм клипмейкер Алан Бадоев шөгыльләнә. Кастинг, җырлау мөмкинлегеннән бигрәк, даны зур күкрәк, зифа гәүдә төзелешенә нигезләнгән төркемнең асыл сыйфатларына нигезләнергә охшап тора. Анда катнашкан кызларның күбесе бирелгән сораулар, «моны эшлә» кебек ише тәкъдимнәрдән шаккатып кайткан. Мисалга, «продюсер белән интим мөнәсәбәткә керергә ризамы», «интим прическа ясатасыңмы», «хәзер үк чишенә аласыңмы», «гыйффәтлегең бармы» ише сораулар кемне генә кыен хәлгә калдырмас икән? Мәнә күрербез инде озаклый җиңүчеләрен...

Сәхифәне Гөлнара ҖӘЛИЛОВА әзерләде



«КЫЗЛАРЫҢ БОЗЫККА БАСКАН»

Авыл баласының мал-туар карап, хайваннар арасында кайнашуы беркемгә дә яңалык түгел. Югары Ослан районының Яңа Болгар авылы халкы Лилиянең эш-гамәлләренә аның кечкенә чагыннан ук соклана. Үзләренең кәҗә бәтиләренә исемнәр кушу дисеңме, аларга күз тимәсен өчен колакларын тишеп алкалар тагуы... Кыз аннары фермага атлар карарга йөри башлый. Әнә шулай мәктәпне тәмамлаганчы мал-туардан аерылмый ул.

ТӘКЪДИР СЫНАВЫ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Бервакыт фермада бер атның үлеп китүен Лилия бик авыр кичерә. Аңа берәүнең дә ярдәм итә алмаганын күргән кыз мәктәптән соң ветеринария институтына укырга керергә хыяллана башлый. Ул 9-10 нчы сыйныфларны Казандагы 10 нчы интернат-мәктәптә тәмамлый. Шәһәргә килгәч тә конюшня эзләп табып, атларның ялларын чистартырга, аларны ашатырга йөри. Аның ветеринария институтын сайлавына авылдашлары гына түгел, сыйныфташлары да гаҗәпләнми. Әмма зооинженерлар әзерли торган факультетта белем алырга туры килә аңа. Аннан соң Питрәчтәге Званка авылындагы кымыз ясау цехында ат саву эшенә китә. Лилия атларның ни дәрәҗәдә акыллы булуына шунда тагын бер кат инана. «Ул чакта кул белән сава идек әле. Атларның көн саен үз тәртипләрен белеп, кеше сыман, чиратка тезелүенә исләр китәрлек. Гагра, Татьяна, Башкирка... беркайчан да үз урыннарын бутамыйлар иде», – дип сөйли ул. Атлар яратуы Лилия Сафинаны Казан ипподромына китерә. Ул башта арбалы атта йөгерүче, аннары бригадир булып эшли башлый. Сабантуйларда, төрле ярышларда Лилия беренчелекне бирми. Беренче Президент М.Шәймиевне дә еш утыртып йөртә ул. Башына ат типкән чаклары да, егылган вакытлары да була аның. Нишлисең, ат дагалаган чактагы тояк исләренә хәтле яраткан кызның гайрәтен берни дә чигерә алмый ул вакытта.

Лилия үзе белән бергә эшләгән Казан егете Рафаэльгә кияүгә чыга. Берничә елдан яшь парны сөендереп, игезәк кызлар – Алсу белән Ләйсән дөньяга аваз сала. Ана кеше телләре ачылган сабыйларының ике яшьтә ишетми башлауларына игътибар итә. Балаларымның колаклары ишетми, дип, табибка алып барса: «Мамаша, не надо прийти готовым диагнозом», – дип, аны борып кайтарып җибәрәләр. Лилия елый-елый кабат невропатологка китә. Анысы балаларның чыннан да ишетмәүләрен әйтә. Туганнары әлеге хәлне Лилиянең атта йөрүеннән дә күрә. Әмма танышлары аңа багучыга барып карарга киңәш бирә. Берничә кешегә барып караганнан соң, арадан берсе: «Балаларың бозыкка баскан. Үлемнән сезне олы хайван саклап калган. Син аларны дәвалый алмыйсың. Тәмле ашат, матур киендер, кулларына буяу бир», – дип озатып кала.

Кызлар икесе дә саңгыраулар мәктәбен тәмамлый. Лилия аларны укыту өчен бөтен көчен куя. Алсу – театр училищесының рәссам-бутафор бүлеген (рәсемдә), Ләйсән сәнгать училищесын тәмамлый. Бүгенге көндә мәдәният һәм сәнгать университетында да укый. Кызларның иҗат җимешләренә сокланып туймаслык. Алар рәсем ясау һәм гамәли сәнгать буенча «Идел – Урал» төбәкара инвалидлар конкурсларыннан Гран-при алып кайтканнар. Казанда узган бәйгеләрдә дә һәрвакыт беренче урыннарны яулыйлар. Кечкенәләре Мәрьям, беренче сыйныфта гына укуга карамастан, тырыш, булдыклы бала. Гимнастикага йөри, музыка мәктәбендә балалайка классында укый.

Әлеге гаилә күпләргә үрнәк булырлык. Ире Рафаэльне, үзенең каенанасы Әминә белән каенатасы Фатихны мактап туймый Лилия. Ата-ана гаиләсендә хөкем сөргән җылылык аларга да күчкән.

Лилия яраткан эшеннән аерылса да, аның күңеле һаман да ипподромга ашкына. Бәйрәмнәрдә ат чабышларын караганда йөрәге җилкенеп, ярсып куя аның.

«Бала сөймәс иргә барма икән...»

«Без яшь чакта егетеңнең кем икәнлеген беләсең килсә, бурычка акча сорап йә үзең аңа бурычка акча биреп сынарга кушалар иде. Яшьлек – юләрлек бит ул. Кем генә алай тикшереп карагандыр инде аны. Мин дә беренче кулымнан тоткан егеткә гашыйк булып, институтымны тәмамлаган гына килеш, беркем сүзенә колак салмый, кияүгә чыгып куйдым. Унбиш ел буе бер рәхәт тә күрмәгән хатын-кыз буларак, мин егетләрне башкача сынап карарга кушар идем...

Фото бизәү өчен бирелә

ГЫЙБРӘТ ӨЧЕН

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

Ярты ел чамасы очрашып йөргәннән соң кияүгә чыгарга тәкъдим ясаган Илназга: «Юк!» – дип әйтә алмадым. Әти-әни сүзенә дә колак салмый, күрәчәгемә ашкындым. Үзе башлап сөйләмәсә дә, гаиләсе турында сүз катсаң, ул һәрвакыт сүзне икенчегә бора иде.

Бик зурлап туй үткәргәннән соң, иремнең әбибабасы йортында яши башладык. Әнисе вафат, әтисе турында берни әйткән кеше булмады. Йөргән вакытта эчми-тартмый торган Илназ, өйләнешкәннән соң озак үтмәде, кәеф-сафа корып, соң кайткалый башлады. Үпкәләп сүз куертсаң, ипи шүрлегенә дә менеп төшәргә күп сорамый иде. Яшәвебезгә сигез ай чамасы булгач, мин көмәнле икәнлегемне әйтеп куандырмакчы идем дә, Илназның чырае тагын да караңгыланды. Яшь булуын сәбәп итеп, аңа үпкәләмәскә тырышып, сабыйны күргәч үзгәрер әле дип яшәдем. Улыбыз тугач хәлемне дә белмәгән ир, ике көн үткәч, тәпи юып туйганнан соң килде. Тагын бар үпкәмне онытып, бар да яхшы булыр дигән өметтә өйгә ашкындым.

Кайткач, татлы итеп йоклаган сабыемның ак биләүләрен сүтеп җибәрдем дә Илназның күзләренә карадым. Ә ул күзләрдә шатлык та, ярату да, сөенеч тә юк иде. Минем аптыраулы карашымны тоеп: «Миңа көндәш туды», – диде дә телевизор каршына барып утырды.

Кайчан да булса бер яратыр, яшь бит әле, аңлап бетермидер дип, аны кичерергә тырыштым. Үсә төшкәч тә улыбызга әллә ни исе китмәде. Бала еласа яисә аңа кагылып кына китсә дә җене котырып, акыра башлый иде. Шуларның нәтиҗәседер, улым яшь ярымда гына көчкә тотынып йөри башлады, күпме хастаханә юлларын таптаганнан соң гына, дүрт яшендә теле ачылды. Неврология буенча бер кочак чире булган балам белән эшкә чыгу, гомумән, мөмкин хәл түгел иде. Әлбәттә, әти-әнием бердәнбер кызлары белән бердәнбер оныкларын мохтаҗлыкта яшәтмәделәр. Аерым яши башлагач, тормышыбыз җайланып китмәсме дип, фатирын да, машинасын да алып бирделәр. Эчеп, теләсә кайда аунап кешелектән чыга башлаган Илназны эчкечелектән дәвалап, аерым яши башладык. Тик боларның берсе дә аның балага карата мөнәсәбәтен үзгәртмәде. Аек чагында да баланың һәрбер шуклыгына аның йодрыгы төйнәлә иде. Мин дә бик арага кермәскә тырыштым. Малай кешегә кырыс әти тәрбиясе зыянга булмас, янәсе. Башка мәңге тапмас идем, дигән сүзем булса да, утызларны узгач, табигатьнең бер хикмәтедерме, Илназ да, мин дә бер үк теләктә булып, календарь буенча санап, кыз алып кайттык.

Бөтен дөньябыз түгәрәк дип шатланып озак яшәргә туры килмәде. Ата игътибарының нәрсә икәнлеген белмәгән улыбызга минем дә игътибар көннән-көн кимеде. Дүрткә-бишкә укыган Риязыбызның укуы да начарланды, тәртибендә дә үзгәрешләр сизелә башлады. Укытучылардан, ата-аналардан канәгатьсезлек сүзләре ишетеп, Илназ Риязны тотып кыйный иде. Ярты ел шул рәвешле яшәгәннән соң, улыбызны мәктәпкә бөтенләй китермәскә куштылар. Табиблар анда җитди психик тайпылыш таптылар. Биләүдәге вакыттан ук ата назы, ата тәрбиясе күрмәгән улыбыз бүген инвалид. Мин аны гына гаепләмим, иң зур гаеп минем үземдә. Булмаган мәхәббәтне сатып алып булмый шул.

Аерылышкач та тыныч кына яшәргә ирек бирмәде ирем. Минем әти-әни бүләк иткән фатир белән машинаның яртысын суд аша алырга йөри. Ә беркөнне миңа үзенең сөенечен әйтеп шалтыратты, ниһаять, ул үзе теләгән – бала таба алмый торган хатын-кызны очраткан... Мин ни диярга да белмәдем. Нинди түбән, вак җан белән гомер иткәнмен бит!

Унбиш ел күргәннәремнән чыгып кызларга киңәшем шул: бала сөймәс иргә бармагыз! Ә ничек сынап карарга дисәгез, йөргән вакытта ук балалы туганнарыгыз белән таныштырыгыз, балалар уйный торган җирләрдә йөргәләгез. Бала сөйгән кеше дөньяның бизәге булган сабыйларга барыбер игътибар итми калмый».

